МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.02.2016 г.Казань № 15/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык төлек министрлыгының 2016 елның
15 гыйнварындагы “2016 елга Татарстан Республикасы
агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль
бюджеттан алына торган акчалар хисабына
субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында”
№ 1/2-пр боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 28 декабрендәге “Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына Россия кредит оешмаларыннан алынган кредитлар һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларыннан алынган займнар буенча процентларны түләүдә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен федераль бюджеттан субсидияләрне бирү һәм бүлү тәртипләрен раслау турында” № 1460 карарын үтәү максатында

**б о е р ы к  б и р ә м:**

1.Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык төлек министрлыгының 2016 елның 15 гыйнварындагы “2016 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алына торган акчалар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” № 1/2-пр боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Боерыкның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 1.9., 1.10., 1.11. пунктчаларын өстәргә:

“1.9. 2016 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан кала), оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына һәм кулланучылар кооперациясе оешмаларына 2009-2016 елларда 1 елга кадәрле чорга Россия кредит оешмаларында алынган кредитлар һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларыннан алынган займнар буенча процентларны түләүдә чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр бирү тәртибе (1 кушымта);

1.10. 2016 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала), оешу-хокукый

рәвешенә бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына һәм кулланучылар кооперациясе оешмаларына 2 елдан 15 елга кадәрле чорга алынган инвестиция кредитлары буенча процентларны түләүдә чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр бирү тәртибе (2 кушымта);

1.11. 2016 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм кррестьян (фермер) хуҗалыкларына 8 елга кадәрле чорга алынган кредитлар һәм займнар буенча процентларны түләүдә чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр бирү тәртибе (3 кушымта)".

2. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министрның беренче урынбасары Н.Л. Титовны җаваплы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
16.02.2016 №15/2-пр боерыгына
карата 1 кушымта

2016 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә
(шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм
авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан кала),
оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы
оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына һәм кулланучылар
кооперациясе оешмаларына 2009-2016 елларда 1 елга кадәрле чорга
Россия кредит оешмаларында алынган кредитлар һәм авыл
хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларыннан алынган
займнар буенча процентларны түләүдә чыгымнарның
бер олешен каплау буенча субсидияләр бирү
ТӘРТИБЕ

1. Бу Тәртип 2016 елда 2009-2016 елларда 1 елга кадәрле чорга Россия кредит оешмаларыннан һәм “Үсеш һәм тышкы икътисади эшчәнлек банкы (Внешэкономбанк)” дәүләт корпорациясеннән алынган кредитлар һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларыннан алынган займнар буенча процентларны түләүдә чыгымнарныц бер өлешен каплау максатларында федераль бюджет акчалары хисабыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала), оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына һәм кулланучылар кооперациясе оешмаларына (алга таба – бурычка алучылар) бирелә.

3. Субсидияләр Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтү максатларында бирелә, түбәндәге чыгымнарның бер өлешен каплауга бәйле рәвештә:

а) 2012 елның 31 декабренә кадәр 1 елга кадәрге чорга төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча:

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан кала) һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына, 2009 елның 1 гыйнварыннан 2012 елның 31 декабренә булган чорга төзелгән шартнамәләр буенча, – ягулык-майлау материаллары, авыл хуҗалыгы техникасы, машиналары, җайланмалары һәм яңгыр яудыра һәм су сибә торган аппаратлар, насос станцияләре өчен запас частьлар һәм аларны ремонтлау материаллары, минерал ашламалар, үсемлекләрне, терлек азыгын саклау чаралары, ветеринария препаратлары һәм Россия Федерациясе Авыл

хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлеккә туры китереп, сезонлы эшләр үткәрү өчен бүтән матди ресурсларны сатып алуга, шулай ук яшь авыл хуҗалыгы терлекләрен сатып алуга һәм авыл хуҗалыгы продуктларын иминиятләштергәндә иминият кертемнәрен түләүгә;

оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмаларына белән кулланучылар кооперациясе оешмаларына, 2009 елның 1 гыйнварыннан 2012 елның 31 декабренә булган чорга төзелгән шартнамәләр буенча, – беренчел һәм сәнәгый эшкәртү өчен үзебезнең илдә җитештерелгән авыл хуҗалыгы чималын сатып алуга;

б) 2013 елның 1 гыйнварыннан башлап 1 елга кадәрге чорга 2015 елның 31 июленә кадәр төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча:

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан кала) һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә үсемлекчелекнең кече тармагын үстерү максатларына;

оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмаларына белән кулланучылар кооперациясе оешмаларына, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә беренчел һәм сәнәгый эшкәртү өчен авыл хуҗалыгы чималын сатып алуга;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан кала) һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына, – Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә терлек азыгы, ветеринария препаратлары, яшь авыл хуҗалыгы терлекләре сатып алуга, шулай ук терлекчелекнең кече тармагын үстерү максатларына;

оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмаларына белән кулланучылар кооперациясе оешмаларына, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә терлекчелек продуктларын беренчел һәм сәнәгый эшкәртү өчен авыл хуҗалыгы чималын сатып алуга, сөт продуктларын җитештерүгә бәйле булган транспорт хезмәтләре өчен түләүгә;

в) 2015 елның 1 августыннан башлап 1 елга кадәрге чорга төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча:

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан кала) һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә үсемлекчелекнең кече тармагын үстерү максатларына;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан кала) һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә терлекчелекнең кече тармагын үстерү максатларына;

авыл хуҗалыгы продуктларын беренчел һәм (яки) алга таба (сәнәгый) эшкәртүне гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан кала),крестьян (фермер) хуҗалыкларына, оешмаларга һәм шәхси эшмәкәрләргә, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә сөтчелек буенча терлекчелекнең кече тармагын үстерү максатларына;

авыл хуҗалыгы продуктларын беренчел һәм (яки) алга таба (сәнәгый) эшкәртүне гамәлгә ашыручы оешмаларга һәм шәхси эшмәкәрләргә һәм кулланучылар кооперациясе оешмаларына, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә, беренчел һәм (яки) алга таба (сәнәгый) эшкәртү өчен авыл хуҗалыгы чималын сатып алуга һәм беренчел һәм (яки) алга таба (сәнәгый) эшкәртү өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләреннән терлекчелек продуктлары, үсемлекчелек продуктлары (яшелчәчелек, бакчачылык, виноградчылык, бәрәңге һәм ябык грунттагы продуктлар) чималын сатып алуга;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан кала) һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә, үсемлекчелектә селекция-орлыкчылык үзәкләрен һәм терлекчелектә селекция-генетика үзәкләрен үстерү максатларына;

г) авыл хуҗалыгы продуктларын беренчел һәм (яки) алга таба (сәнәгый) эшкәртүне гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре, оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан алынган кредитлар (займнар) буенча, – финанслау чыганакларын бурычка алучының акционерлары тарафыннан бирелгән займнар яки облигацияле займнар тәшкил итүче һәм шушы пунктның “а”-“в” пунктчаларында билгеләнгән максатлар нигезендә, мондый кредитлардан (займнардан) файдалану чоры шушы пунктчаларда күрсәтелгән чорны узып китмәгән шарт белән, 2015 елның 1 гыйнварыннан соң тотылган чыгымнарны рефинанслаулауга (каплауга).

4. Түбәндәгечә төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча кредитлардан (займнардан) файдалану чорын озынайту турында 2012 елның 31 декабренә кадәр килешү имзаланган очракта:

2009 елның 1 гыйнварыннан башлап, шушы Тәртипнең 3 пунктының “а” пунктчасында каралган кредитлар (займнар) буенча шартнамәләргә карата, – мондый шартнамәләр буенча чыгымнарның бер өлешен каплау аларны 6 айга кадәрге чорга озынайту юлы белән гамәлгә ашырыла;

Татарстан Республикасында 2009 елда булып узган корылык аркасында авыл хуҗалыгы продуктлары зыян күргән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан кала) белән крестьян (фермер) хуҗалыклары арасында 2009 елда төзелгән шартнамәләргә карата, – шушы Тәртипнең 3 пунктының “а” пунктчасында каралган кредитлар

(займнар) буенча, чыгымнарның бер өлешен каплау мондый шартнамәләрне түбәндәге чорларга озынайтып гамәлгә ашырыла:

1 елга кадәр – терлекчелек продуктлары белән берлектә үсемлекчелек продуктларын җитештерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан кала) белән крестьян (фермер) хуҗалыклары өчен;

3 елга кадәр – 2008 ел өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең финанс-икътисади торышы турында хисап мәгълүматлары белән расланган, бары тик үсемлекчелек продуктларын генә җитештерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан кала) белән крестьян (фермер) хуҗалыклары өчен;

авыл хуҗалыгы продуктлары 2010 елда Татарстан Республикасында булып узган корылык йогынтысы аркасында зыян күргән, корылык факты буенча башкарма хакимият органнары билгеләнгән тәртиптә гадәттән тыш хәл тәртибен керткән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары белән шушы Тәртипнең 3 пунктындагы “а” пунктчасында каралган кредитлар (займнар) буенча һәм 2012 елның 31 декабренә кадәр төзелгән шартнамәләр буенча, – чыгымнарның бер өлешен каплау 3 елга кадәрле чорга озынайтылган шундый шартнамәләр буенча гамәлгә ашырыла.

Шушы Тәртипнең 3 пунктының “б” пунктчасында каралган, 2014 елда төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исмлек нигезендә үсемлекчелекнең кече тармагын үстерү максатларына алынган кредитлардан (займнардан) файдалану чорын озынайту турында 2014 елның 1 июленнән башлап 2015 елның 1 июленә кадәр килешү имзаланган очракта, чыгымнарның бер өлешен каплау шушы шартнамәләр буенча аларны 1 елдан артмаган чорга озынайтып гамәлгә ашырыла.

5. Шушы Тәртипнең 4 пункты нигезендә шартнамәне озынайтуның чик чоры билгеләнгән очракта, шушы Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән чорлар чикләрендә озынайту исәпкә алынмый.

6. Субсидияләр түбәндәгечә бирелә:

а) шушы Тәртипнең 3 пунктының “а” пунктчасында каралган кредитлар (займнар) буенча, – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслаулау ставкасының (исәпкә алу ставкасының) 80 проценты күләмендә, ә мөгезле эрек терлек итеп һәм сөт җитештерү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан кала) тарафыннан алынучы аталган кредитлар (займнар) буенча, – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслаулау ставкасының (исәпкә алу ставкасының) 100 проценты күләмендә;

б) шушы Тәртипнең 3 пунктындагы “б” һәм “в” пунктчаларында каралган кредитлар (займнар) буенча, – Россия Федерациясе Үзәк банкының

рефинанслаулау ставкасының (исәпкә алу ставкасының) өчтән ике өлеше күләмендә, ә сөт җитештерү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан кала) тарафыннан сөт терлекчелеген үстерү өчен алынган атлаган кредитлар (займнар) буенча, – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслаулау ставкасының (исәпкә алу ставкасының) 80 проценты күләмендә, ә мөгезле эре терлек итен җитештерү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан кала) тарафыннан, мөгезле эре терлек итен беренчел һәм (яки) алга таба (сәнәгый) эшкәртүн дә кертеп, ит терлекчелеген үстерү, шулай ук терлекчелектә селекция-орлыкчылык үзәкләрен һәм терлекчелектә селекция-генетика үзәкләрен үстерү өчен алынган аталган кредитлар (займнар) буенча, – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслаулау ставкасының (исәпкә алу ставкасының) 100 проценты күләмендә;

в) шушы Тәртипнең 3 пунктындагы “а”-“в” пунктчаларында каралган кредитлар (займнар) буенча 2015 елда субсидияләр бирелгән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан кала) һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына 2015 ел өчен процентларны (вакытыннан алда түләнгән проңентларны да кертеп) түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен, – түбәндәге формула буенча билгеләнә торган субсидияләү ставкасы (ССIj) күләмендә:

$$ССIj=СТреф \times 1,1 + КС-INF,$$

биредә:

СТреф – 2015 елның 1 гыйнварына карата Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслаулау ставкасы (исәпкә алу ставкасы), ә 2015 елның 1 августыннан башлап – кредит шартнамәсен (займ шартнамәсен) яки кредиттан (займнан) файдалану өчен түләү күләмен үзгәртүгә бәйле кредит шартнамәсенә (займ шартнамәсенә) карата өстәмә килешү төзү датасына карата;

КС – 2015 елның 1 гыйнварына карата Россия Федерациясе Үзәк банкының төп ставкасы, ә 2015 елның 1 августыннан башлап – кредит шартнамәсен (займ шартнамәсен) яки кредиттан (займнан) файдалану өчен түләү күләмен үзгәртүгә бәйле кредит шартнамәсенә (займ шартнамәсенә) карата өстәмә килешү төзү датасына карата;

INF – Федераль дәүләт статистикасы белешмәләренә карап, 2014 ел өчнг инфляция дәрәҗәсе.

г) Бурычка алучыларга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен бирелә торган акчалар бурычка алучыларның кредитлар (займнар) буенча процентларны түләүгә киткән фактик чыгымнарыннан, шулай ук бурычка алучы белән Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек

министрлыгы (алга таба – Министрлык) арасында төзелә торган килешүдә күрсәтелгән агымдагы елга күрсәтелүче акчаларның чик күләмдәне исәп-хисап күләменнән артып китәргә тиеш түгел.

8. Чыгымнарның бер өлешен каплау өчен акчалар бурычка алучыларга алар тарафыннан төп бурычны каплау һәм саналган процентларны түләү буенча йөкләмәләр үтәлгән шартта бирелә. Төп бурычны каплау һәм саналган процентларны түләү буенча йөкләмәләрне бозу нәтиҗәсендә саналган һәм түләнгән процентларны түләүгә киткән чыгымнарның бер олешен каплау өчен субсидияләр бирелми.

Бурычка алучы кредитны (займны) чит ил валютасында алган очракта, чыгымнарның бер өлешен каплау өчен акчалар чит ил валютасына карата кредит буенча процентларны түләү датасына Россия Федерациясе Үзәк банкы билгеләгән рубль курсыннан чыгып бирелә. Чыгымнарның бер өлешен каплауга карата акча күләмен исәпләгәндә чит ил валютасында алынган кредит (займ) буенча чик күләме елына 10,5 процент күләмендә, ә 2015 елның 1 гыйнварыннан соң алынган кредитлар (займнар) буенча елына 10 проценттан артмаган дәрәҗәдә билгеләнә торган процент ставкасы кулланыла.

9. Субсидияләрнең күләме Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслаулау ставкасы (исәпкә алу ставкасы) буенча максатчан билгеләнеше буенча файдаланылган, кредит шартнамәсен (займ шартнамәсен) төзү датасына, ә кредиттан (займнан) файдалану өчен түләү күләме үзгәртелүгә бәйле кредит шартнамәсенә (займ шартнамәсенә) карата өстәмә килешү төзегән очракта, – кредит шартнамәсенә (займ шартнамәсенә) карата өстәмә килешү төзү датасына гамәлдә булган кредит (займ) суммасыннан чыгып исәпләнә.

10. Шушы Тәртипнең 3 пунктындагы “а”-“г” пунктчаларында каралган кредитлар (займнар) буенча чыгымнарның бер өлешен каплау өчен акчалар бирелсен өчен, бурычка алучы килештерү өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә) түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык раслаган рәвештә, түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирелү турында гариза;

кредит оешмасы тарафыннан таныкланган кредит шартнамәсенең (займ шартнамәсенең), кредит (займ) алу турында ссуда счетыннан өземтәнең, аның буенча түләү һәм проңентларны түләү графигының күчермәләре;

товарларны сатып алуга һәм хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәләрнең, накладная кәгазьләренең яки накладнаялар реестрының (әгәр накаладная кәгазенең саны 20 данәдән артып китсә), авыл хуҗалыгы продуктларын иминиятләштерү шартнамәләренең һәм авыл хуҗалыгы продуктларын иминиятләштергәндә иминият кертемнәрен түләүгә карата счетларның бурычка алучы тарафыннан таныкланган күчермәләре – кредиттан файдалану дәрәҗәсенә карап;

кредит оешмасы тарафыннан таныкланган аванс түләүләрен кертеп, товарларга һәм хезмәтләргә түләү буенча банктан өземтәләрнең һәм түләү йөкләмәләренең күчермәләре;

Министрлык раслаган рәвештә субсидияләрнең күләм исәпләмәсе (субсидияләр элек финансланган чорлар өчен яңадан исәпләнми торган, тапшырылган исәпләмәләр буенча түләнә);

Министрлык раслаган рәвештә субсидияләрнең күләменә карата планлы исәпләмә;

Министрлык раслаган рәвештә кредитны (займны) каплау һәм аның буенча процентларны түләү графигы.

11. Шушы Тәртипнең 10 пунктында каралган, шушы Тәртипнең 3 пунктындагы “а”-“в” пунктчаларында каралган кредитлар (займнар) буенча документлар 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап бурычка алучы тарафыннан Министрлыкка кредит шартнамәсенең гамәлдәге вакыты тәмамланганнан соң 6 айга кадәрге чорга тапшырыла.

Идарә бурычка алучы тапшырган документларны тикшерә, 2 көнлек чорда субсидияләрнең күләм исәпләмәләрен килештерә һәм аларны бурычка алучыга кайтарып бирә;

субсидияләрнең күләме кредит шартнамәсен (займ шартнамәсен) төзү датасына, ә кредиттан (займнан) файдалану өчен түләү күләме үзгәртелүгә бәйле кредит шартнамәсенә (займ шартнамәсенә) карата өстәмә килешү төзегән очракта, – кредит шартнамәсенә (займ шартнамәсенә) карата өстәмә килешү төзү датасына гамәлдә булган Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслаулау ставкасы (исәпкә алу ставкасы) буенча исәпләнә.

Шушы Тәртипнең 10 пунктында күрсәтелгән, Идарәдә килештерелгән документларны бурычка алучы Министрлыкка агымдагы айның 1 нче көненнән алып 20 нче көненә кадәр тапшыра.

Министрлык:

бурычка алучы тапшырган документларны тикшерә, бурычка алучының гаризасын гаризалар керү тәртибендә теркәү дәфтәрендә терки, ул дәфтәр номерана, тегелә һәм Министрлыкның мөһере белән беркетелә, һәм бурычка алучыга гаризаны карап тикшерүгә кабул итү турында яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, аны кабул итүдән баш тарту турында, кабул ителгән документларны теркәгән көннән соң өч эш көнендә, язмача белдерүнамә җибәрә;

өч эш көне дәвамында субсидияләрне алу өчен теркәлгән документларны карап тикшерә;

бурычка алучыга кредитлар (займнар) буенча процентларны түләүдә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирелүдән баш тарткан очракта, теркәү дәфтәрендә тиешле язуны терки, шул ук вакытта 10 көн дәвамында бурычка алучыга тиешле язма белдерүнамә җибәрә;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә субсидияләрне бирүдән баш тарткан очракта, аларны субсидияләрне алу өчен билгеләнгән таләпләргә туры китергәннән соң, субсидияләрне алу өчен авыл хуҗалыгы товар

житештерүчесе тарафыннан тапшырылган зарури документларны яңадан карап тикшерә;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре белән Министрлык раслаган рәвештә Субсидияләр бирелү турында килешү (алга таба – Килешү) төзи, анда субсидия алучыларның Министрлык белән финанс контрольлеге буенча дәүләт органнары тарафыннан субсидияләрне алучыларның аларның бирелү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүгә ризалык бирүе субсидияләр бирелүнең мәҗбүри шарты буларак санала.

Субсидияләрне бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

шушы Тәртипнең 10 пунктында күрсәтелгән документның булмавы;

бюджет йөкләмәләре лимитында калдык өлеш булмау.

Субсидияләрне бирүдән баш тарту законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять кылына.

12. Бурычка алучы, үз ихтыяры буенча, бурычка алучының салымнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча түләнмәгән бурычлары булмавы хакында салым органыннан белешмә тапшыра (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала).

Әгәр дә бурычка алучы үз ихтыяры буенча аталган документны тапшырмаса, Министрлык, ведомствоара гарызнамә юлы белән, шул исәптән бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан файдаланып, электрон рәвештә Федераль салым хезмәтеннән бурычка алучының салымнарны, җыемнарны, Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнарын бозган өчен пеняларны һәм штрафларны түләүдә бурычы булу (булмавы) турында белешмәләрне сората һәм ала (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала).

13. Министрлык бюджет акчаларын төп бүлүче булып тора һәм, Министрлык раслаган рәвештә хисапланган субсидияләрнең күләме нигезендә, субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән башлап 10 көнлек чорда, үзенең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган лицевой счетыннан бурычка алучыларның исәп-хисап счетларына акча күчерә.

14. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет керемнә кире кайтарылырга тиеш.

15. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет керемнә кире кайтарылырга тиеш.

16. Бу Тәртипнең 14 һәм 15 пунктларында күрсәтелгән бюджет акчаларын федераль бюджет керемөнә ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

17. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

18. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе Россия кредит оешмаларыннан алынган кредитлар һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларыннан алынган займнар буенча процентларны түләүдә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләрдән ирекле рәвештә баш тарткан очракта, акчалар Россия Федерациясе бюджетына һәм Татарстан Республикасы бюджетына хисап елыннан соң килүче елның 1 декабренә кадәр кайтарып бирелергә тиеш.

19. Министрлык счетларында хисаплы финанс елында файдаланылмаган акчалар калган очракта, алар Россия Федерациясе бюджетына һәм Татарстан Республикасы бюджетына хисап елыннан соң килүче елның 1 декабренә кадәр кайтарып бирелергә тиеш.

20. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык аларның җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләнә. Закон бозучыларга карата закон нигезендә күздә тотылган җаваплылык чаралары кулланыла.

21. Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
______________№_______ боерыгына
карата 2 кушымта

2016 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә
(шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала),
оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы
оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына һәм кулланучылар
кооперациясе оешмаларына 2 елдан 15 елга кадәрле чорга алынган
инвестиция кредитлары буенча процентларны түләүдә чыгымнарның
бер өлешен каплау буенча субсидияләр бирү
ТӘРТИБЕ

1. Бу Тәртип 2016 елда 2014-2016 елларда 2 елдан алып 15 елга кадәрге чорга Россия кредит оешмаларыннан һәм "Үсеш һәм тышкы икътисади эшчәнлек банкы (Внешэкономбанк)" дәүләт корпорациясеннән алынган кредитлар һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларыннан алынган займнар буенча процентларны түләүдә чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында федераль бюджет акчалары хисабыннан субсидияләр (алга таба, тиешенчә – кредит оешмалары, кредитлар (займнар), чыгымнарның бер өлешен каплау, субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтү максатларында бирелә, түбәндәге чыгымнарның бер өлешен каплауга бәйле рәвештә:

а) түбәндәгечә алынган инвестиция кредитлары (займнары) буенча: авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала), оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмалары, крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары тарафыннан кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча, түбәндәгечә төзелгән очракта:

2004 елның 1 гыйнварыннан башлап 2012 елның 31 декабренә кадәр 2 елдан 8 елга кадәр төзелгән шартнамәләр буенча (ит терлекчелеге һәм (яки) сөт җитештерү белән шөгыльләнүче, оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмаларыннан кала), – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә җайланма, махсус транспорт, махсус техника, йөк автомобильләрен, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын газ-мотор ягулыгына күчерү өчен җайланмалар һәм нәселле продуктлар (материал) сатып алуга, шулай ук күп еллык утыртмаларга нигез салуга, күп еллык утыртмалар өчен прививкалау комплексларын төзү һәм үзгәртеп кору, терлекчелек комплексларын (фермаларны), терлекчелек һәм терлек азыгын җитештерү объектларын, бәрәңге, яшелчә һәм җиләк-җимеш саклана торган биналарны, ябык грунтта җимешле-яшелчәле продуктлар җитештерү буенча теплица комплексларын, җитен һәм җитен җепселен эшкәртү объектларын, итне салкында саклый торган биналарны, салкында эшкәртүне һәм ит белән сөт продуктларын

саклауны исәпкә алып, авыл хуҗалыгы терлекләрен һәм сөтне кабул итеп алу һәм (яки) беренчел эшкәртү буенча пунктларны төзү, үзгәртеп кору һәм модернизацияләү һәм югары протеинлы авыл хуҗалыгы культураларын (соя, бодай, арыш, кукуруз, рапс, нут һәм мисыр тарысы) тирәнтен эшкәртү буенча объектларны төзү өчен;

2004 елның 1 гыйнварыннан башлап 2008 елның 1 гыйнварына кадәр 2 елдан 8 елга кадәрге чорга, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә авыл хуҗалыгы техникасын сатып алу өчен;

2009 елның 1 гыйнварыннан башлап 2012 елның 31 декабренә кадәр 8 елга кадәрге чорга, – авыл җирлегендә яшәүче һәм эшләүче гражданнарга торак төзелеше өчен;

2010 елның 1 гыйнварыннан башлап 2012 елның 31 декабренә кадәр 8 елга кадәрге чорга, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә машиналар, җайланмалар һәм яңгыр яудыра торган һәм су сиптерә торган аппаратлар, насос станцияләре сатып алу өчен;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала) 2008 елның 1 гыйнварыннан башлап 2012 елның 31 декабренә кадәр 10 елга кадәрге чорга төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча һәм 2008 елның 1 гыйнварыннан 2012 елның 31 декабренә кадәр төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә 15 елга кадәрге чорга ит һәм (яки) сөт терлекчелеген үстерүгә алынган очракта, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә авыл хуҗалыгы техникасын сатып алу өчен;

оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә, бөртекле һәм май культураларын эшкәртүне, саклауны һәм күчереп төяүне башкаручы оешмаларга 2010 елның 1 гыйнварыннан башлап 2012 елның 31 декабренә кадәр 10 елга кадәрге чорга төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча:

бөртекле һәм май культураларын эшкәртү, саклау һәм күчереп төяү өчен куәтләрне төзү, үзгәртеп кору һәм модернизацияләү өчен;

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә бөртекле һәм май культураларын эшкәртү, саклау һәм күчереп төяү өчен җайланмалар сатып алу өчен (монтажлау һәм эшләтеп җибәрү-җайлау эшләрен дә кертеп);

оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә агросәнәгать оешмаларына түбәндәгечә төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча:

2009 елның 1 гыйнварыннан башлап 2012 елның 31 декабренә кадәр 8 елга кадәрге чорга, – шикәр заводларын төзү, үзгәртеп кору һәм модернизацияләү өчен;

2010 елның 1 гыйнварыннан башлап 2012 елның 31 декабренә кадәр 8 елга кадәрге чорга, – мелиоратив системаларны, заводларны, авыл хуҗалыгы

үсемлекләренең орлыкларын әзерләү һәм эшкәртү комплексларын төзү, үзгәртеп кору, модернизацияләү һәм торгызу өчен;

оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә, товар (сәнәгый) балыкчылыгын гамәлгә ашыручы оешмаларга 2007 елның 1 гыйнварыннан башлап 2011 елның 31 декабренә кадәрге чорга төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча:

5 елга кадәрге чорга – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә токымла балык материалы, товар (сәнәгый) балыкчылык өчен техника һәм җайланма сатып алуга;

8 елга кадәрге чорга – товар (сәнәгый) балыкчылыгын гамәлгә ашыру буенча комплексларны (фермаларны) төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә;

оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә, йортка ияләштерелгән балык төрләрен һәм токымнарын үрчетүне гамәлгә ашыручы оешмаларга, 2012 елның 1 гыйнварыннан башлап 2012 елның 31 декабренә кадәр төзелгән түбәндәге кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча:

5 елга кадәрге чорга – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә йортка ияләштерелгән балык төрләрен һәм токымнарын үрчетү өчен токымлы балык материалы, техника һәм җайланма сатып алуга;

8 елга кадәрге чорга – йортка ияләштерелгән балык төрләрен һәм токымнарын үрчетү буенча комплекслар (фермалар) төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә;

ит терлекчелеге һәм (яки) сөт җитештерү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала), оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә агросәнәгать оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына 2004 елның 1 гыйнварыннан башлап 2012 елның 31 декабренә кадәр 15 елга кадәрге чорга төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә җайланма, махсус транспорт, махсус техника, йөк автомобильләрен, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын газ-мотор ягулыгына күчерү өчен җайланмалар һәм нәселле продуктлар (материал) сатып алуга, шулай ук терлекчелек комплексларын (фермаларны), терлекчелек һәм терлек азыгын җитештерү объектларын, итне салкында саклый торган биналарны, салкында эшкәртүне һәм ит белән сөт продуктларын саклауны исәпкә алып, авыл хуҗалыгы терлекләрен һәм сөтне кабул итеп алу һәм (яки) беренчел эшкәртү буенча пунктларны төзү, үзгәртеп кору һәм модернизацияләү өчен;

б) 2013 елның 1 гыйнварыннан башлап 2015 елның 31 июленә кадәр түбәндәгеләр белән төзелгән инвестицияле кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча:

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына, оешу-хокукый

рәвешенә бәйсез рәвештә агросәнәгать оешмаларына 2 елдан 8 елга кадәрге чорга;

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә бәрәңге, яшелчә һәм җиләк-җимеш саклагычны, ябык грунтта җимеш-яшелчә продуктларын җитештерү буенча теплица комплексларын, онга ваклау-ярма, икмәк пешерү һәм май сәнәгате предприятиеләрен, шикәр заводларын, яшелчә, җиләк-җимеш продуктларын, бәрәңге эшкәртү буенча куәтләрне, җитен һәм җитен җепселен эшкәртү объектларын, авыл хуҗалыгы үсемлекләренең орлыкларын әзерләү буенча комплексларны, шикәр чөгендеренең саклагыч тышча белән тышланган орлыкларын җитештерү заводларын төзүгә, үзгәртеп коруга, модернизацияләүгә, югары протеинлы авыл хуҗалыгы культураларын тирәнтен эшкәртү буенча объектларны, бөртекле һәм май культураларын эшкәртү, саклау һәм күчереп төяү өчен объектларны төзүгә, күп еллык утыртмаларны утыртуга һәм карап тотуга, күп еллык утыртмалар өчен прививка комплексларын төзүгә, үзгәртеп коруга, шулай ук мелиоратив системаларны төзүгә, үзгәртеп коруга, модернизацияләүгә һәм торгызуга (мелиоратив системаларны төзүгә, үзгәртеп коруга, модернизацияләүгә һәм торгызуга алынган инвестицияле кредитларны субсидияләү 2013 елның 31 декабренә кадәрге чор өчен башкарыла);

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына, оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә агросәнәгать оешмаларына (ит терлекчелеге һәм (яки) сөт җитештерү белән шөгыльләнүче оешмалардан кала) 2 елдан 8 елга кадәрге чорга, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә, терлекчелек комплексларын (фермаларын), объектларын, ит сәнәгате предприятиеләрен, авыл хуҗалыгы терлекләрен һәм сөтне (салкында эшкәртүне һәм ит белән сөт продуктларын саклауны да кертеп) кабул итеп алу, беренчел һәм (яки) алга таба (сәнәгый) эшкәртү буенча пунктларны, сөт, сыр һәм сыер мае продуктларын җитештерү предприятиеләрен, сүл эшкәртү һәм киптерү буенча цехларны һәм кишәрлекләрне, комбикорма предприятиеләрен һәм цехларын төзүгә һәм үзгәртеп коруга, нәселле продуктлар сатып алуга, шулай ук терлекчелекнең кече тармагын үстерү максатларына;

ит терлекчелеге белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына, оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә агросәнәгать оешмаларына 15 елга кадәрле чорга, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә, ит токымлы мөгезле эре терлекнең нәселле продуктларын (материалын) сатып алуга, ит терлекчелеге өчен комплексларны (фермаларны), объектларны, ит эшкәртү предприятиеләрен, авыл хуҗалыгы терлекләрен һәм сөтне, салкында эшкәртүне һәм ит белән сөт продуктларын саклауны да кертеп, кабул итеп

алу, беренчел һәм (яки) алга таба (сәнәгый) эшкәртү буенча пунктларны төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә, шулай ук ит терлекчелеген үстерү максатларына;

сөт җитештерү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына, оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә агросәнәгать оешмаларына 15 елга кадәрге чорга, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә, терлекчек комплексларын (фермаларны), объектларны, сөтне (салкында эшкәртүне һәм ит белән сөт продуктларын саклауны да кертеп) кабул итеп алу, беренчел һәм (яки) алга таба (сәнәгый) эшкәртү буенча пунктларны, сөт, сыр һәм сыер мае продуктларын җитештерү предприятиеләрен, сүл эшкәртү һәм киптерү буенча цехларны һәм кишәрлекләрне төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә, комбикорма предприятиеләрен һәм цехларын төзүгә һәм үзгәртеп коруга, нәселле продуктлар сатып алуга, шулай ук терлекчелекнең кече тармагын үстерү максатларына;

в) 2015 елның 1 гыйнварыннан башлап төзелгән инвестицияле кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына, оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә агросәнәгать оешмаларына 8 елга кадәрге чорга, – үсемлекчелектә биотехнология продуктларын җитештерү буенча объектларны (үсемлекләрдә чир кузгатучыларны ачыклау өчен диагностика җыелмалары), терлекчелектә һәм терлек азыгын җитештерү өлкәсендә биотехнология продуктларын (терлек азыгының сыйфатын яхшырту өчен биоөстәлмәләр (аминокислоталар, терлек азыгы өчен аксым, ферментлар, витаминнар, пробиотиклар), азык-төлек һәм эшкәртү сәнәгатендә биотехнология продуктларын (крахмаллар һәм глюкозалы-җиләк-җимешле ширбәтләр, ферментлар һәм сөт, май, ит эшкәртү эшләре өчен микроорганизмнар, органик кислоталар (лимон, сөт һәм серкә), азык-төлек чималын тирәнтен эшкәртүдән алынган продуктлар, биоягулык) җитештерү буенча объектларны төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә;

г) 2015 елның 1 августыннан башлап төзелгән инвестицияле кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча:

авыл хуҗалыгы продуктларын беренчел һәм (яки) алга таба (сәнәгый) эшкәртүне гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына, оешмаларга һәм шәхси эшмәкәрләргә 2 елдан алып 8 елга кадәрге чорга, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә, бәрәңге, яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр саклагычны, ябык грунтта җимешле-яшелчәле продуктлар җитештерү буенча теплица комплексларын, он тарттыру-ярма, икмәк пешерү һәм май сәнәгате

предприятиеләрен, шикәр заводларын, җимешле-яшелчәле, җиләк продуктларын һәм бәрәңгене эшкәртү буенча куәтләрне, җитен һәм җитен җепселен эшкәртү объектларын, авыл хуҗалыгы үсемлекләренең орлыкларын әзерләү буенча комплексларны, шикәр чөгендеренец саклагыч тышча белән тышланган орлыкларын җитештерү буенча заводларны төзүгә, үзгәртеп коруга, модернизацияләүгә, югары протеинлы авыл хуҗалыгы культураларын тирәнтен эшкәртү буенча объектлар, бөртек һәм май культураларын эшкәртү, саклау һәм күчереп төяү өчен куәтләрне төзүгә, күп еллык утыртмаларны утырту һәм карап тәрбияләү өчен, күп еллык утыртмалар өчен прививка комплексларын төзүгә һәм үзгәртеп коруга, шулай ук башка төрле инвестиция чыгымнары төрләре өчен, шул исәптән, техника, җайланма, автомобиль сәнәгате эшләнмәләрен сатып алуга;

авыл хуҗалыгы продуктларын беренчел һәм (яки) алга таба (сәнәгый) эшкәртүне гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына, оешмаларга һәм шәхси эшмәкәрләргә 2 елдан 8 елга кадәрле чорга, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә, терлекчек комплексларын (фермаларны), объектларны, ит эшкәртү предприятиеләрен, авыл хуҗалыгы терлеген һәм сөтне (ит белән сөт продуктларын салкында эшкәртүне һәм саклауны да кертеп) кабул итеп алу, беренчел һәм (яки) алга таба (сәнәгый) эшкәртү буенча пунктларны, сөт, сыр һәм сыер мае продуктларын җитештерү предприятиеләрен, сүл эшкәртү һәм киптерү буенча цехларны һәм кишәрлекләрне төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә, комбикорма предприятиеләрен һәм цехларын төзүгә һәм үзгәртеп коруга, нәселле продуктлар сатып алуга, шулай ук башка төрле инвестиция чыгымнары төрләре өчен, шул исәптән, техника, җайланма, автомобиль сәнәгате эшләнмәләрен сатып алуга;

авыл хуҗалыгы продуктларын беренчел һәм (яки) алга таба (сәнәгый) эшкәртүне гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына, оешмаларга һәм шәхси эшмәкәрләргә 15 елга кадәрле чорга (ит терлекчелеген үстерүгә юнәлдерелгән кредитлар буенча), – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә, ит токымындагы мөгезле эре терлекнең нәселле продуктларын (материалын), ит эшкәртү предприятиеләрен, итне (ит продуктларын салкында эшкәртүне һәм саклауны да кертеп) кабул итеп алу, беренчел һәм (яки) алга таба (сәнәгый) эшкәртү буенча пунктларны сатып алуга, шулай ук башка төрле инвестиция чыгымнары төрләре өчен, шул исәптән, техника, җайланма, автомобиль сәнәгате эшләнмәләрен сатып алуга;

авыл хуҗалыгы продуктларын беренчел һәм (яки) алга таба (сәнәгый) эшкәртүне гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына,

оешмаларга һәм шәхси эшмәкәрләргә 15 елга кадәрле чорга (сөт терлекчелеген үстерүгә юнәлдерелгән кредитлар буенча), – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә, терлекчек комплексларын (фермаларны), объектларны, сөтне (сөт продуктларын салкында эшкәртүне һәм саклауны да кертеп) кабул итеп алу, беренчел һәм (яки) алга таба (сәнәгый) эшкәртү буенча пунктларны, сөт, сыр һәм сыер мае продуктларын җитештерү предприятиеләрен, сүл эшкәртү һәм киптерү буенча цехларны һәм кишәрлекләрне төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә, комбикорма предприятиеләрен һәм цехларын төзүгә һәм үзгәртеп коруга, нәселле продуктлар сатып алуга, шулай ук башка төрле инвестиция чыгымнары төрләре өчен, шул исәптән, техника, җайланма, автомобиль сәнәгате эшләнмәләрен сатып алуга;

авыл хуҗалыгы продуктларын беренчел һәм (яки) алга таба (сәнәгый) эшкәртүне гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына, оешмаларга һәм шәхси эшмәкәрләргә 2 елдан 8 елга кадәрле чорга, – үсемлекчелектә селекция-орлыкчылык үзәкләрен төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә, ә 15 елга кадәрге чорга, – терлекчелектә селекция-генетика үзәкләрен төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә, шулай ук, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә, башка төрле инвестиция чыгымнары төрләре өчен, шул исәптән, техника, җайланма, автомобиль сәнәгате эшләнмәләрен сатып алуга;

Россия оешмаларына 2 елдан башлап 8 елга кадәрге чорга, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә, күмәртәләп-бүлү үзәкләрен төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә, мондый үзәкләр дигәндә авыл хуҗалыгы продуктларын, чималны һәм азык-төлекне саклау, эшләү, беренчел эшкәртү, кабул итү, төргәкләү һәм сату өчен билгеләнгән, шул исәптән Россия Федерациясендә мохтаҗ халык катламнарына азык-төлек белән ярдәм итүнең эчке системасында, эчке һәм тышкы инженерлык-техник тәэминат челтәрләрен үз эченә алучы автоматлаштырылган электрон мәгълүмати һәм исәп-хисап системаларын файдаланып, ветеринар һәм фитосанитар контрольлек өчен биналар, төзелмәләр һәм корылмалар комплексы аңлашыла, шулай ук техника, җайланма, автомобиль сәнәгате эшләнмәләрен сатып алуга;

д) шушы пунктның “а”-“г” пунктчаларында каралган кредитларны (займнарны) рефинанслаулау өчен алынган кредитлар (займнар) буенча, кредитлардан (займнардан) файдалануның суммар чоры шушы пунктчаларда күрсәтелгән чорларны узып китмәү шарты белән;

е) авыл хуҗалыгы продуктларын беренчел һәм (яки) алга таба (сәнәгый) эшкәртүне гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре, оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан алынган кредитлар (займнар) буенча, – шушы пунктның “г” пунктчасында билгеләнгән максатларга туры китереп тотылган, финанс чыганаклары булып

бурычка алучының акционерлары тарафыннан бирелгән займнар яки облигацияле займнар торган һәм 2015 елның 1 гыйнварыннан соң башкарылган чыгымнарны рефинанслаулау (каплау) өчен, мондый кредитлардан (займнардан) файдалану вакыты шушы пунктчаларда күрсәтелгән вакытны узмау шарты белән.

3. 2012 елның 31 декабренә кадәр түбәндәгечә төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча кредитлардан (займнардан) файдалану чорын озынайту турында килешү имзаланган очракта:

2004 елның 1 гыйнварыннан башлап шушы Тәртипнең 2 пунктындагы “а” пунктчасының икенче кызыл юлында каралган кредитлар (займнар) буенча чыгымнарның бер өлешен каплау мондый шартнамәләр буенча аларны 3 елдан артмаган чорга озынайтып гамәлгә ашырыла;

авыл хуҗалыгы продуктлары 2010 елда Татарстан Республикасында булып узган корылык йогынтысы нәтиҗәсендә зыян күргән, башкарма хакимият органы билгеләнгән тәртиптә корылык факты буенча гадәттән тыш хәл тәртибен керткән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, шул исәптән шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражаннарга, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына шушы Тәртипнең 2 пунктындагы “а” пунктчасында каралган кредитлар (займнар) буенча һәм 2012 елның 31 декабренә кадәр төзелгән шартнамәләр буенча, чыгымнарның бер өлешен каплау мондый шартнамәләр буенча аларны 3 елдан артмаган чорга озынайтып гамәлгә ашырыла;

2015 елның 1 гыйнварыннан башлап 2015 елның 31 декабренә кадәр шушы Тәртипнең 2 пунктындагы “а”-“в” пунктчаларында каралган кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча кредитлардан (займнардан) файдалану чорын озынайту турында килешү имзаланган очракта, чыгымнарның бер өлешен каплау мондый шартнамәләр буенча аларны 1 елдан артмаган чорга озынайтып гамәлгә ашырыла.

4. Шушы Тәртипнең 3 пунктына туры китереп, шартнамәне озынайтуның чик күләмдәге чорын билгеләгәндә шушы Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән чорлар чикләрендә башкарылган озынайту исәпкә алынмый.

5. Чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр бурычка алучыларга түбәндәге шартларда бирелә:

а) бурычка алучы белән Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) арасында инвестиция кредитлары (займнары) буенча проңентларны түләүдә чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирелү турында килешү төзелгәннән соң;

б) алар тарафыннан төп бурычны һәм саналган процентларны түләү һәм кредиттан (займнан) максатчан билгеләнеше буенча файдалануга карата йөкләмәләр үтәлү шарты белән.

Төп бурычны каплау һәм саналган процентларны түләү буенча йөкләмәләр бозылган очракта, субсидияләр бирелми.

6. Бурычка алучыларга процентларны түләүдә чыгымнарның бер өлешен каплау түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

а) шушы Тәртипнең 2 пунктындагы “а” пунктчасында каралган инвестиция кредитлары (займнары) буенча, – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәпкә алу ставкасының) 80 проценты күләмендә, ә аталган, мөгезле эре терлек итен һәм сөт җитештерү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала) һәм оешу-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмалары тарафыннан сөт һәм ит терлекчелеген үстерүгә, шулай ук авыл хуҗалыгы техникасын (2008 елның 1 гыйнварыннан соң 10 елга кадәрге чорга төзелгән кредит шартнамәләре буенча һәм 2008 елның 1 гыйнварыннан башлап 2012 елның 31 декабренә кадәр төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча, ит һәм (яки) сөт терлекчелеген үстерүгә 15 елга кадәрле чорга алынган инвестиция кредитлары (займнары) буенча, – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәпкә алу ставкасының) 100 проценты күләмендә), ит һәм сөт токымындагы мөгезле эре терлекнең нәселле продуктларын (материалын) сатып алуга, мөгезле эре терлекләрнең терлекчелек комплексларын (фермаларны), мөгезле эре терлек өчен терлек азыгы җитештерү объектларын, мөгезле эре терлекне сую һәм беренчел эшкәртү өчен ит эшкәртү предприятиеләрен һәм мөгезле эре терлекне һәм сөтне кабул итеп алу һәм беренчел эшкәртү буенча, яисә бары тик мөгезле эре терлекне һәм сөтне кабул итү буенча, яисә бары тик беренчел эшкәртү буенча пунктларны төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә алынган кредитлар (займнар) буенча, – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәпкә алу ставкасының) 100 проценты күләмендә;

б) шушы Тәртипнең 2 пунктындагы “б” һәм “в” пунктчаларында каралган кредитлар (займнар) буенча, – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәпкә алу ставкасының) өчтән ике өлеше күләмендә, аталган, сөт җитештерү, ит терлекчелеген үстерү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан кала) тарафыннан алынган кредитлар (займнар) буенча, – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәпкә алу ставкасының) 100 проценты күләмендә;

в) шушы Тәртипнең 2 пунктындагы “г” пунктчасында каралган кредитлар (займнар) буенча, – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәпкә алу ставкасының) өчтән ике өлеше күләмендә, ә ит һәм сөт терлекчелеген үстерүгә, шулай ук үсемлекчелектә селекция-орлыкчылык үзәкләрен һәм терлекчелектә селекция-генетика үзәкләрен үстерүгә алынган кредитлар (займнар) буенча, – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәпкә алу ставкасының) 100 проценты күләмендә.

7. Субсидияләрнең күләме Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслаулау ставкасы (исәпкә алу ставкасы) буенча максатчан билгеләнеше буенча файдаланылган, кредит шартнамәсен (займ

шартнамәсен) төзү датасына, ә кредиттан (займнан) файдалану өчен түләү күләме үзгәртелүгә бәйле кредит шартнамәсенә (займ шартнамәсенә) карата өстәмә килешү төзегән очракта, – кредит шартнамәсенә (займ шартнамәсенә) карата өстәмә килешү төзү датасына гамәлдә булган кредит (займ) суммасыннан чыгып исәпләнә.

Бурычка алучы кредитны (займны) чит ил валютасында алган очракта, чыгымнарның бер өлешен каплау өчен акчалар чит ил валютасына карата кредит буенча процентларны түләү датасына Россия Федерациясе Үзәк банкы билгеләгән рубль курсыннан чыгып бирелә.

Чыгымнарның бер өлешен каплауга карата акча күләмен исәпләгәндә чит ил валютасында алынган кредит (займ) буенча чик күләме елына 10,5 процент күләмендә, ә 2015 елның 1 гыйнварыннан соң алынган кредитлар (займнар) буенча елына 10 проңенттан артмаган дәрәҗәдә билгеләнә торган процент ставкасы кулланыла.

8. Шушы Тәртипнең 2 пунктындагы “а”-“г” пунктчаларында каралган кредитлар (займнар) буенча чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсдияләр алу буенча бурычка алучы, кредит (займ) буенча процентларны фактта түләгәннән соң кимендә 90 көн эчендә Министрлыкның Татарстан Республикасы муниңипаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә) түбәндәге документларны тапшыра:

а) Министрлык раслаган рәвештә, түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирелү турында гариза;

б) түләү йөкләмәсенең (яки бүтән төрле банк документының) һәм кредит оешмасы тарафыннан таныкланган, бурычка алучының ссуда счетыннан кредит алуы турында өземтәнең яки займ алуын раслый торган документның күчермәләре;

в) кредит оешмасы тарафыннан таныкланган, агымдагы айда процентларны түләгәнлеккә түләү йөкләмәләренең (яки бүтән төрле банк документының) күчермәләре;

г) кредит оешмасы тарафыннан таныкланган, кредитны (займны) каплау һәм аның буенча процентларны түләү графигы;

д) шушы Тәртипнең 10 пунктына туры китереп, кредит (займ) акчаларыннан исемлек буенча максатчан файдаланылуын раслый торган документларның күчермәләре, – кредиттан файдалану дәрәҗәсенә карап;

е) Министрлык раслаган рәвештә билгеле бер чор өчен субсидияләр исәпләмәсе (субсидияләр элегрәк финансланган чорлар өчен кире исәпләнми торган, тапшырылган исәпләмәләр буенча түләнә);

ж) салым органында (Код по КНД 1120101) рәвеше буенча таныкланган, салым түләүләре буенча түләнмәгән түләүләрнең булмавын раслый торган документларның күчермәләре;

з) Министрлык раслаган рәвештә кредит буенча акчаларны үзләштерү турында белешмә.

9. Бурычка алучы, үз ихтыяры буенча, бурычка алучының салымнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча түләнмәгән бурычлары булмавы

хакында салым органыннан белешмә тапшыра (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала).

Әгәр дә бурычка алучы үз ихтыяры буенча аталган документны тапшырмаса, Министрлык, ведомствоара гарызнамә юлы белән, шул исәптән бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан файдаланып, электрон рәвештә Федераль салым хезмәтеннән бурычка алучының салымнарны, җыемнарны, Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнарын бозган өчен пеняларны һәм штрафларны түләүдә бурычы булу (булмавы) турында белешмәләрне сората һәм ала (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала).

10. Бурычка алучы тарафыннан таныкланган, кредиттан (займнан) файдалану дәрәҗәсенә карап, кредиттан (займнан) максатчан файдалануны раслый торган документларның күчермәләре:

Россия Дәүләт стандартының 1993 елның 30 декабрендәге № 301 карары белән расланган ОК005-93 Гомумроссия продуктлар классификаторында билгеләнгән авыл хуҗалыгы техникасын, җайланмасын, махсус транспорт һәм махсус техника сатып алуга алынган кредитлар (займнар) буенча:

кредит оешмасы тарафыннан таныкланган, аванс түләүләрен дә кертеп, авыл хуҗалыгы техникасы, җайланмасы, махсус транспорт һәм махсус техника өчен түләгәнлекне раслый торган түләү йөкләмәләренең күчермәләре;

кредит оешмасы тарафыннан таныкланган, җайланма өчен түләүдә аккредитив ачуны раслый торган түләү йөкләмәләренең һәм (яки) документларның күчермәләре;

авыл хуҗалыгы техникасы, җайланмасы, махсус транспорт һәм махсус техника сатып алуга (лизинг) шартнамәләрнең күчермәләре;

авыл хуҗалыгы техникасы, җайланмасы, махсус транспорт һәм махсус техника сатып алуга товар-транспорт накладная кәгазьләренең, счет-фактураларның күчермәләре;

авыл хуҗалыгы техникасын, җайланмасын, махсус транспортны һәм махсус техниканы кабул итеп алу-тапшыру актларының күчермәләре (№ОС-1, №ОС-1б, №ОС-15 рәвешләре)*

юл хәрәкәте иминлеге буенча дәүләт инспекциясе органнарында һәм дәүләт техника күзәтчелеге органнарында теркәлүе турындагы тамга белән транспорт чарасының, үзйөрешле машинаның паспорт күчермәләре.

Нәселле продуктлар салып алуга алынган кредитлар (займнар) буенча:

кредит оешмасы тарафыннан таныкланган, аванс түләүләрен кертеп, нәселле продуктлар (материал) өчен түләгәнлекне раслый торган түләү

---

Искәрмә: * №ОС-1а, №ОС-15, №КС-2, №КС-3, №ОС-1 рәвешләре буенча субсидияләрнең суммасын хисаплаганда (максатчан файдалануны раслау) НДС исәпкә алып, максатчан файдалануга кабул ителәләр

йөкләмәләренең күчермәләре**;

кредит оешмасы тарафыннан таныкланган, нәселле продуктлар (материал) өчен түләүгә түләү йөкләмәләренең һәм (яки) аккредитив ачуны раслый торган документларның күчермәләре;

нәселле продуктлар (материал) сатып алуга карата контракт күчермәсе;

валютаны күчерүне раслый торган свифт хәбәрләре күчермәләре;

йөк таможня декларациясе күчермәсе (законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә йөк таможня декларациясен рәсмиләштергәннән соң бирелә);

импорт алыш-бирешенең паспорт күчермәсе;

импорт алыш-бирешенең паспорт торышы турында белешмә.

Төзү, үзгәртеп кору һәм модернизацияләү өчен алынган кредитлар (займнар) буенча:

төзелешнең титул исемлеге күчермәсе;

объектны төзүгә һәм (яки) үзгәртеп коруга, һәм (яки) модернизацияләүгә җыелма смета күчермәсе.

Эшләрне подряд ысулы белән башкарганда:

кредит оешмасы тарафыннан расланган, технологик җайланмалар, бүтән эшләр (проект эшләре, экспертиза, техник күзәтчелек) өчен түләгәнлекне һәм эшләрне башкаруга карата, шул исәптән аванс түләүләре буенча подрядчыларга акча күчергәнлекне раслый торган түләү йөкләмәләренең күчермәләре;

технологик җайланма китертү, подряд эшләрен, бүтән эшләрне башкару (проект эшләре, экспертиза, техник күзәтчелек) буенча шартнамәләрнең, чыгымнарның сметасы һәм төзү-монтажлау эшләрен башкару графигы күчермәләре, алар бурычка алучы һәм подрядчы тарафыннан таныкланган булырга тиеш;

төзелеш материаллары, эшләр һәм юридик затлар белән физик затларның хезмәтләре өчен түләүне раслый торган кредит оешмасы таныклаган түләү йөкләмәләре күчермәләре;

төзелеш материаллары китертүгә шартнамәләрнең күчермәләре;

товар-транспорт накладнаяларының, техник җайланма алуга счет-фактураларның күчермәләре;

җайланманы монтажлауга кабул итеп алу-тапшыру турында актларның күчермәләре (№ОС-15)*

Бурычка алучы төзелеш материаллары өчен түләгәндә:

бурычка алучы тарафыннан төзелеш материаллары алынуга карата товар-транспорт накладнаялары күчермәләре;

подрядчы тарафыннан төзелеш материалларын аларны бәягә кертү өчен тапшыруга карата документларның күчермәләре, №КС-3* рәвешендә;

бурычка алучы таныклаган, башкарылган эшләрне кабул итеп алу

---

** кредитны чит ил валютасында алганда һәм аны сумнарда кулланганда инвестицияле кредитның максатчан файдаланылуын раслый торган документларның исемлеге сумнарда алынган инвестиция

кредитыннан максатчан файдалануны раслау өчен билгеләнгән документлар исемлегенә туры килә.
турында актларның күчермәләре (№КС-2 рәвеше)*;

бурычка алучы һәм подрядчы тарафыннан таныкланган, башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнар турында белешмәләрнең күчермәләре;

Эшләрне хуҗалык ысулы белән башкарганда:

төзелеш материаллары, эшләр һәм юридик затлар белән физик затларның хезмәтләре өчен түләүне раслый торган кредит оешмасы таныклаган түләү йөкләмәләре күчермәләре;

җаваплы затларны билгеләү турында боерыкның күчермәсе һәм эшләрне хуҗалык ысулы белән үткәрү графигы һәм эшләр күләме;

җыелма смета исәпләмәсенең һәм локаль сметаларның күчермәләрне, эшләрне хуҗалык ысулы белән башкару турында боерык, башкарылган эшләрнең актлары күчермәләре (№КС-2 рәвеше)*;

башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнар турында белешмәләр (№КС-3)*;

технологик җайланма китертүгә, аерым эшләрне (проект эшләрен, экспертизаны, техник күзәтчелекне дә кертеп) подряд ысулы белән башкаруга карата шартнамәләрнең күчермәләре;

технологик җайланма өчен түләгәнлекне һәм подрядчыларга акча күчерүне раслый торган, аванс түләүләрен дә кертеп, кредит оешмасы тарафыннан таныкланган түләү йөкләмәләренең күчермәләре.

Җайланмаларны чит ил валютасында сатып алуны раслый торган документлар**:

чит ил җайланмасын сатып алуга карата контрактның күчермәсе;

җайланма өчен түләүгә түләү йөкләмәләренең һәм (яки) аккредитив ачуны раслый торган документларның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

житкерүчегә валютада акча күчергәнлекне раслый торган дебет авизо яки валютаны күчереп, свифт хәбәрләренең күчермәләре;

йөк таможня декларациясе күчермәсе (законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә йөк таможня декларациясен рәсмиләштергәннән соң бирелә);

импорт алыш-биреше паспорты күчермәсе;

импорт алыш-бирешенең паспорты торышы турында белешмә;

җайланманы монтаждауга кабул итеп алу-тапшыру турында актларның күчермәләре (№ОС-15 рәвеше)*.

Крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары өчен:

төзелешнең титул исемлеге күчермәсе;

---

* №ОС-1а, №ОС-15, №КС-2, №КС-3, №ОС-1 рәвешләре буенча субсидияләрнең суммасын хисаплаганда (максатчан файдалануны раслау) НДС исәпкә алып, максатчан файдалануга кабул ителәләр

** кредитны чит ил валютасында алганда һәм аны сумнарда кулланганда инвестицияле кредитның максатчан файдаланылуын раслый торган документларның исемлеге сумнарда алынган инвестиция кредитыннан максатчан файдалануны раслау өчен билгеләнгән документлар исемлегенә туры килә.

объектны төзүгә һәм (яки) үзгәртеп коруга, һәм (яки) модернизацияләүгә җыелма смета күчермәсе;

технологик җайланма китертү, подряд эшләрен, бүтән эшләрне башкару (проект эшләре, экспертиза, техник күзәтчелек) буенча шартнамәләрнең, чыгымнарның сметасы һәм төзү-монтажлау эшләрен башкару графигы күчермәләре.

Эшләрнең графигы үтәлү дәрәҗәсенә карап бурычка алучы тапшыра торган документлар:

подряд ысулы белән башкарылган эшләр, бүтән төрле эшләр (проект эшләре, экспертиза, техник надзор) һәм технологик җайланма өчен, эшләрне хуҗалык ысулы белән башкарганда төзелеш материаллары һәм чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләгәнлекне раслый торган түләү йөкләмәләренең, аванс түләүләрен дә кертеп, кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

башкарылган эшләр актларының күчермәләре;

бинаны (корылманы) файдалануга кабул итеп алу-тапшыру турында актларның күчермәләре (төзелеш беткәннән соң бирелә, шул ук вакытта субсидия бурычка алучыга эшләрнең этаплары башкарылу дәрәҗәсенә карап түләнә).

Җайланманы чит ил валютасында сатып алуны раслый торган документлар**:

чит ил җайланмасын сатып алуга карата контрактның күчермәсе;

җайланма өчен түләүгә түләү йөкләмәләренең һәм (яки) аккредитив ачуны раслый торган документларның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валюта күчерүне раслау турында свифт хәбәрләренең күчермәләре;

йөк таможня деклараңиясе күчермәсе (законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә йөк таможня декларациясен рәсмиләштергәннән соң бирелә);

импорт алыш-биреше паспорты күчермәсе;

импорт алыш-бирешенең паспорты торышы турында белешмә;

җайланманы монтажлауга кабул итеп алу-тапшыру турында актларның күчермәләре (№ОС-15 рәвеше)*.

Крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары өчен:

төзелешнең титул исемлеге күчермәсе;

---

* №ОС-1а, №ОС-15, №КС-2, №КС-3, №ОС-1 рәвешләре буенча субсидияләрнең суммасын хисаплаганда (максатчан файдалануны раслау) НДС исәпкә алып, максатчан файдалануга кабул ителәләр

** кредитны чит ил валютасында алганда һәм аны сумнарда кулланганда инвестицияле кредитның максатчан файдаланылуын раслый торган документларның исемлеге сумнарда алынган инвестиция кредитыннан максатчан файдалануны раслау өчен билгеләнгән документлар исемлегенә туры килә.

объектны төзүгә һәм (яки) үзгәртеп коруга, һәм (яки) модернизацияләүгә җыелма смета күчермәсе;

технологик җайланма китертү, подряд эшләрен, бүтән эшләрне башкару (проект эшләре, экспертиза, техник күзәтчелек) буенча шартнамәләрнең, чыгымнарның сметасы һәм төзү-монтажлау эшләрен башкару графигы күчермәләре.

Эшләрнең графигы үтәлү дәрәҗәсенә карап бурычка алучы тапшыра торган доументлар:

подряд ысулы белән башкарылган эшләр, бүтән төрле эшләр (проект эшләре, экспертиза, техник надзор) һәм технологик җайланма өчен, эшләрне хуҗалык ысулы белән башкарганда төзелеш материаллары һәм чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләгәнлекне раслый торган түләү йөкләмәләренең, аванс түләүләрен дә кертеп, кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

башкарылган эшләр актларының күчермәләре;

бинаны (корылманы) файдалануга кабул итеп алу-тапшыру турында актларның күчермәләре (төзелеш беткәннән соң бирелә, шул ук вакытта субсидия бурычка алучыга эшләрнең этаплары башкарылу дәрәҗәсенә карап түләнә).

Җайланманы чит ил валютасында сатып алуны раслый торган документлар**:

чит ил җайланмасын сатып алуга карата контрактның күчермәсе;

җайланма өчен түләүгә түләү йөкләмәләренең һәм (яки) аккредитив ачуны раслый торган документларның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валюта күчерүне раслау турында свифт хәбәрләренең күчермәләре;

йөк таможня декларациясе күчермәсе (законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә йөк таможня декларациясен рәсмиләштергәннән соң бирелә);

импорт алыш-биреше паспорты күчермәсе;

импорт алыш-бирешенең паспорты торышы турында белешмә;

бинаны (корылманы) кабул итеп алу-тапшыру турында актларның (№ОС-1а)* һәм (яки) төп чараларның үзгәртеп корылган, модернизацияләнгән обүектларын кабул итеп алу-тапшыру актларының күчермәләре (төзелеш беткәннән соң бирелә, шул ук вакытта субсидия бурычка алучыларга эшләрнең этаплары башкарылу дәрәҗәсенә карап түләнә).

* №ОС-1а, №ОС-15, №КС-2, №КС-3, №ОС-1 рәвешләре буенча субсидияләрнең суммасын хисаплаганда (максатчан файдалануны раслау) НДС исәпкә алып, максатчан файдалануга кабул ителәләр

** кредитны чит ил валютасында алганда һәм аны сумнарда кулланганда инвестицияле кредитның максатчан файдаланылуын раслый торган документларның исемлеге сумнарда алынган инвестиция кредитыннан максатчан файдалануны раслау өчен билгеләнгән документлар исемлегенә туры килә.

Күп еллык утыртмалар утыртуга:

утыртма материал һәм (яки) шпалерлар урнаштыру очен материаллар өчен түләгәнлекне раслый торган, аванс түләүләрен дә кертеп, түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

төп чараларны кабул итеп алу-тапшыру актларының №ОС-1* рәвеше буенча актлары күчермәләре;

Утырту материалын чит ил валютасында сатып алганлыкны раслый торган документлар**:

утырту материалын салып алуга карата бурычка алучы тарафыннан таныкланган контракт күчермәсе;

утырту материалы өчен түләгәнлекне раслый торган түләү йөкләмәләренең һәм (яки) аккредитив ачылуны раслый торган документларның кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

валюта күчерүне раслау турында свифт хәбәрләренең күчермәләре;

йөк таможня декларациясе күчермәсе (законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә йөк таможня декларациясен рәсмиләштергәннән соң бирелә);

импорт алыш-биреше паспорты күчермәсе;

импорт алыш-бирешенең паспорты торышы турында белешмә;

№ОС-1* рәвеше буенча төп чараларны кабул итеп алу-тапшыру турында актларның күчермәләре.

11. Идарә тарафыннан килештерелгән, шушы Тәртипнең 8 пунктларында күрсәтелгән документларны бурычка алучы Министрлыкка агымдагы айның 1 нче көненнән 20 нче көненә кадәр тапшыра.

Министрлык:

бурычка алучының гаризасын гаризалар керү тәртибендә теркәү дәфтәрендә терки, ул дәфтәр номерана, тегелә һәм Министрлыкның мөһере белән беркетелә;

бурычка алучыга гаризаны карап тикшерүгә кабул итү турында яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, аны кабул итүдән баш тарту турында, кабул ителгән документларны теркәгән көннән соң өч эш көнендә, язмача белдерүнамә җибәрә;

3 эш көне дәвамында бурычка алучы тарафыннан тапшырылган документларны карап тикшерә;

бурычка алучыга субсидияләр бирелүдән баш тарткан очракта, теркәү дәфтәрендә тиешле язуны терки, шул ук вакытта ун көн дәвамында бурычка алучыга тиешле язма белдерүнамә җибәрә.

---

* №ОС-1а, №ОС-15, №КС-2, №КС-3, №ОС-1 рәвешләре буенча субсидияләрнең суммасын хисаплаганда (максатчан файдалануны раслау) НДС исәпкә алып, максатчан файдалануга кабул ителәләр

** кредитны чит ил валютасында алганда һәм аны сумнарда кулланганда инвестиңияле кредитның максатчан файдаланылуын раслый торган документларның исемлеге сумнарда алынган инвестиция кредитыннан максатчан файдалануны раслау өчен билгеләнгән документлар исемлегенә туры килә.

13. Субсидияләрне бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

10 пунктта күрсәтелгән документның булмавы;

бюджет йөкләмәләренең лимитта калдык өлеше булмау.

Субсидияләрне бирүдән баш тарту законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять кылына.

14. Министрлык бюджет акчаларын төп бүлүче булып тора һәм, Министрлык раслаган рәвештә хисапланган субсидияләрнең күләме нигезендә, субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән башлап 10 көнлек чорда, үзенең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган лицевой счетыннан бурычка алучыларның исәп-хисап счетларына акча күчерә.

15. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет керемнәнә кире кайтарылырга тиеш.

16. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет керемнәнә кире кайтарылырга тиеш.

17. Бу Тәртипнең 18 һәм 19 пунктларында күрсәтелгән бюджет акчаларын Татарстан Республикасының бюджет керемнәнә ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

18. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары субсидияләрне алучыларга субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

19. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе Россия кредит оешмаларыннан алынган кредитлар һәм авыл хуҗалыгы кредит

кулланучылар кооперативларыннан алынган займнар буенча процентларны түләүдә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләрдән ирекле рәвештә баш тарткан очракта, акчалар Россия Федерациясе бюджетына һәм Татарстан Республикасы бюджетына хисап елыннан соң килүче елның 1 декабренә кадәр кайтарып бирелергә тиеш.

20. Министрлык счетларында хисаплы финанс елында файдаланылмаган акчалар калган очракта, алар Россия Федерациясе бюджетына һәм Татарстан Республикасы бюджетына хисап елыннан соң килүче елның 1 декабренә кадәр кайтарып бирелергә тиеш.

21. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык аларның җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләнә. Закон бозучыларга карата закон нигезендә күздә тотылган җаваплылык чаралары кулланыла.

22. Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
16.02.2016 №15/2-пр боерыгына
карата 3 кушымта

2016 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм кррестьян (фермер) хуҗалыкларына 8 елга кадәрле чорга алынган кредитлар һәм займнар буенча процентларны түләүдә чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр бирү

ТӘРТИБЕ

1. Бу Тәртип 2016 елда федераль бюджет акчалары хисабыннан 8 елга кадәрге чорга Россия кредит оешмаларыннан һәм "Үсеш һәм тышкы икътисади эшчәнлек банкы (Внешэкономбанк)" дәүләт корпорациясеннән алынган кредитлар һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларыннан алынган займнар буенча процентларны түләүдә чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына (әзерләүче, тәэмин итеп торучы, сатучы (сәүдә), эшкәртүче, хезмәт күрсәтүче) һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына (алга таба – бурычка алучылар) бирелә.

3. Субсидияләр Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтү максатларында бирелә, түбәндәге чыгымнарның бер олешен каплауга бәйле рәвештә:

а) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга, түбәндәгечә төзелгән кредит шартнамәләре (займнар) буенча:

2005 елның 1 гыйнварыннан башлап 2012 елның 31 декабренә кадәр 5 елга кадәрге чорга, – авыл хуҗалыгы өчен кече габаритлы техника, егәрлеге 100 ат көченә кадәр булган тракторлар һәм алар белән агрегатлана торган авыл хуҗалыгы машиналары, йөк ташый торган, тулы массасы 3,5 тоннадан артмаган автомобильләр сатып алуга;

2005 елның 1 гыйнварыннан башлап 5 елга кадәрге чорга, – авыл хуҗалыгы терлекләрен, терлекчелек һәм авыл хуҗалыгы продуктларын эшкәртү өчен җайланма сатып алуга, шулай ук терлекчелек биналарын ремонтлауга, үзгәртеп коруга һәм төзүгә, газ җайланмасын сатып алуга һәм, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан алынган кредитның (займның) гомуми суммасы агымдагы елда бер хуҗалыкка 700 мең сумнан артып китмәгән шарт белән, газ челтәрләренә тоташтыруга;

2007 елның 1 гыйнварыннан башлап 2 елга кадәрге чорга, – ягулык-майлау материаллары, авыл хуҗалыгы техникасын һәм терлекчелек биналарын ремонтлау өчен запас өлешләр һәм материаллар, минерал

ашламалар, үсемлекләрне, терлек азыкларын саклау чаралары, ветеринария препаратлары һәм авыл хуҗалыгы эшләрен башкару өчен башка матди ресурслар, шул исәптән теплицалар, яшь авыл хуҗалыгы терлекләре өчен материаллар сатып алуга, шулай ук, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан алынган кредитның (займның) гомуми суммасы агымдагы елда бер хуҗалыкка 300 мең сумнан артып китмәгән шарт белән, авыл хуҗалыгы продуктларын иминиятләштергән очракта иминият кертемнәрен түләүгә;

2008 елның 1 гыйнварыннан башлап 2012 елның 31 декабренә кадәр 5 елга кадәрге чорга, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслаган исемлек нигезендә, халык кәсепчелеген, авыл җирлегендә сәүдәлекне үстерүне кертеп, авыл җирлегендә туристлыкны (авылда туристлыкны), шулай ук авыл халкына көнкүреш һәм социаль-мәдәни хезмәт күрсәтүгә, кыргый үсүче җимешләрне, җиләкләрне, дару үләннәрен һәм башка азык-төлек һәм агач булмаган урман ресурсларын үстерүгә бәйле юнәлешләрне үстерүгә;

2010 елның 1 гыйнварыннан башлап 2012 елның 31 декабренә кадәр 5 елга кадәрге чорга, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслаган исемлек нигезендә, яңгыр яудыра һәм су сиптерә торган машиналар, җайланмалар һәм аппаратлар, насос станцияләре сатып алуга;

б) крестьян (фермер) хуҗалыкларына түбәндәгечә төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча:

2005 елның 1 гыйнварыннан башлап 2012 елның 31 декабренә кадәр 8 елга кадәрге чорга, – авыл хуҗалыгы техникасы һәм җайланмасы, шул исәптән тракторлар һәм аның белән агрегатлана торган авыл хуҗалыгы машиналары, терлекчелек, кошчылык, терлек азыгы җитештерү өчен кулланыла торган җайланмалар, яңгыр яудыра һәм су сиптерә торган машиналар, җайланмалар һәм аппаратлар, насос станцияләре, йөк автомобильләрен, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын газ-мотор ягулыгына күчерү өчен җайланмалар сатып алуга;

2005 елның 1 гыйнварыннан башлап 8 елга кадәрге чорга, – авыл хуҗалыгы продуктларын саклауга һәм эшкәртүгә, нәселле авыл хуҗалыгы терлекләрен, нәселле продуктлар (материал) сатып алуга, бәрәңге, яшелчә һәм җиләк-җимеш саклый торган биналарны, ябык грунтта җимешле-яшелчәле продуктлар җитештерү буенча комплексларны, терлекчелек комплексларын (фермалар), терлекчелек, терлек азыгын җитештерү объектларын һәм җитенне һәм җитен җепселен эшкәртү буенча объектларны төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә, күп еллык утыртмалар өчен прививка комплексларын төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә һәм күп еллык утыртмаларны һәм виноградлыкларны утыртуга, агымдагы елда алынган кредитның (займның) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 10 миллион сумнан артып китмәү шарты белән, прививка комплексларын төзүне һәм үзгәртеп коруны да кертеп;

2007 елның 1 гыйнварыннан башлап 2 елга кадәрге чорга, – ягулык-майлау материаллары, авыл хуҗалыгы техникасын һәм терлекчелек

биналарын ремонтлау өчен запас өлешләр һәм материаллар, минерал ашламалар, үсемлекләрне, терлек азыкларын саклау чаралары, ветеринария препаратлары һәм сезонлы эшләр башкару өчен башка матди ресурслар, яшь авыл хуҗалыгы терлекләре сатып алуга, шулай ук, агымдагы елда алынган кредитның (займның) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 5 миллион сумнан артып китмәгән шарт белән, авыл хуҗалыгы продуктларын иминиятләштергән очракта иминият кертемнәрен түләүгә;

2008 елның 1 гыйнварыннан башлап 2012 елның 31 декабренә кадәр 5 елга кадәрге чорга, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслаган исемлек нигезендә, халык кәсепчелеген, авыл җирлегендә сәүдәлекне үстерүне кертеп, авыл җирлегендә туристлыкны (авылда туристлыкны), шулай ук авыл халкына көнкүреш һәм социаль-мәдәни хезмәт күрсәтүгә, кыргый үсүче җимешләрне, җиләкләрне, дару үләннәрен һәм башка азык-төлек һәм агач булмаган урман ресурсларын әзерләүгә һәм эшкәртүгә бәйле юнәлешләрне үстерүгә;

в) авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына түбәндәгечә төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча:

2005 елның 1 гыйнварыннан башлап 2012 елның 31 декабренә кадәр 8 елга кадәрге чорга, – техника һәм җайланма (Россиядә һәм чит илдә җитештерелгәнне), шул исәптән терлек азыкларын, инкубатор күкәйләрен, чебешләрне, нәселле бозауларны һәм кош көтүлекләрен ташу өчен махсус транспорт, тракторлар һәм алар белән агрегатлана торган авыл хуҗалыгы машиналары, терлекчеклек, кошчылык, терлек азыгы җитештерү өчен җайланмалар, йөк машиналарын, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын газ-мотор ягулыгына күчерә торган җайланмалар сатып алуга;

2005 елның 1 гыйнварыннан башлап 8 елга кадәрге чорга, – махсус технологик җайланма, суыткыч җайланмасы, авыл хуҗалыгы терлекләре, нәселле продуктлар (материал) сатып алу, шул исәптән аларны кооператив әгъзаларына китерү өчен, бәрәңге, яшелчә һәм җиләк-җимеш саклый торган биналарны, ябык грунтта җимешле-яшелчәле продуктлар җитештерү буенча комплексларны, терлекчелек, терлек азыгы җитештерү объектларын һәм җитен белән җитен җепселен эшкәртү объектларын төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә, базарларны, сәүдә урыннарын, сөтне, итне, яшелчә-җиләк-җимеш продуктларын кабул итеп алу, беренчел эшкәртү һәм саклау буенча пунктларны төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә, шулай ук күп еллык утыртмаларны һәм виноградлыкларны утыртуга, агымдагы елда алынган кредитның (займның) гомуми суммасы бер кооперативка 40 миллион сумнан артып китмәгән шарт белән, күп еллык утыртмалар өчен прививка комплексларын төзүгә һәм үзгәртеп коруга;

2007 елның 1 гыйнварыннан башлап 2012 елның 31 декабренә кадәр 2 елга кадәрге чорга, – авыл хуҗалыгы техникасын һәм җайланмасын ремонтлау өчен запас өлешләр һәм материаллар сатып алуга, шул исәптән аларны кооператив әгъзалары өчен китертүгә;

2007 елның 1 гыйнварыннан башлап 2 елга кадәрге чорга, – сезонлы эшләрне башкару өчен матди ресурслар, яшь авыл хуҗалыгы терлекләре,

сәнәгый эшкәртү өчен үзебезнең илдә җитештерелгән авыл хуҗалыгы чималы (2013 елдан башлап – беренчел һәм сәнәгый эшкәртү өчен авыл хуҗалыгы чималы) сатып алуга, кооператив әгъзалары җитештергән авыл хуҗалыгы продуктларын алга таба аны сату өчен сатып алуга, шулай ук кооперативны оешкан төстә җиһазландыруга һәм, агымдагы елда алынган кредитның (займның) гомуми суммасы бер кооперативка 15 миллион сумнан артып китмәгән шарт белән, аыыл хуҗалыгы продуктларын иминиятләштергәндә иминият кертемнәрен түләүгә;

2008 елның 1 гыйнварыннан башлап 2012 елның 31 декабренә кадәр 5 елга кадәрге чорга, – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслаган исемлек нигезендә, халык кәсепчелеген, авыл җирлегендә сәүдәлекне үстерүне кертеп, авыл җирлегендә туристлыкны (авылда туристлыкны), шулай ук авыл халкына көнкүреш һәм социаль-мәдәни хезмәт күрсәтүгә, кыргый үсүче җимешләрне, җиләкләрне, дару үләннәрен һәм башка азык-төлек һәм агач булмаган урман ресурсларын әзерләүгә һәм эшкәртүгә бәйле юнәлешләрне үстерүгә;

г) шушы пунктның “а”-“в” пунктчаларында каралган кредитларны (займнарны) рефинанслау өчен алынган кредитлар (займнар) буенча, кредитлардан (займнардан) файдалануның гомуми чоры шушы пунктчаларда күрсәтелгән чорлардан артмау шарты белән.

4. 2012 елның 31 декабренә кадәр кертеп, түбәндәгечә төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча кредитлардан (займнардан) файдалану чорын озынайту турында килешү имзаланган очракта:

2005 елның 1 гыйнварыннан башлап, шушы Тәртипнең 3 пунктындагы “а” пунктчасындагы икенче һәм өченче кызыл юлларда каралган кредитлар (займнар) буенча чыгымнарның бер өлешен каплау мондый шартнамәләр буенча аларны 2 елдан артмаган чорга озынайтып гамәлгә ашырыла;

авыл хуҗалыгы продуктлары 2010 елда Татарстан Республикасында булып узган корылык тәэсире нәтиҗәсендә зыян күргән, башкарма хакимият органы корылык факты буенча гадәттән тыш хәл тәртибен керткән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, шул исәптән шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына шушы Тәртипнең 3 пунктындагы “а”-“в” пунктчаларында каралган кредитлар (займнар) һәм 2012 елның 31 декабренә кадәр төзелгән шартнамәләр буенча чыгымнарның бер өлешен каплау мондый шартнамәләр буенча аларны 3 елдан артмаган чорга озынайтып гамәлгә ашырыла.

5. Шушы Тәртипнең 4 пункты нигезендә шартнамәне озынайтуның чик вакытын билгеләгәндә шушы Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән чорлар кысаларында башкарылган озынайту исәпкә алынмый.

6. Субсидияләр түбәндәгечә бирелә:

а) 2012 елның 31 декабренә кадәр төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча, – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәпкә алу ставкасының) 95 проценты күләмендә;

б) 2013 елның 1 гыйнварыннан башлап төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча, – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасыныц (исәпкә алу ставкасының) өчтән ике өлеше күләмендә;

в) 2015 ел өчен төзелгән кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча (вакытыннан алда түләнгән процентларны да кертеп), – Россия Федерациясе Үзәк банкыныц рефинанслау ставкасыныц (исәпкә алу ставкасының) 100 проценты күләмендә.

7. Бурычка алучыларга чыгымнарныц бер өлешен каплау буенча бирелә торган акчалар бурычка алучыларның кредитлар (займнар) буенча процентларны түләүгә фактта киткән чыгымнарыннан артып китәргә тиеш түгел.

8. Чыгымнарның бер өлешен каплау өчен акчалар бурычка алучыларга алар тарафыннан төп бурычны каплау һәм саналган процентларны түләү буенча йөкләмәләр үтәлгән шартта бирелә. Төп бурычны каплау һәм саналган процентларны түләү буенча йөкләмәләрне бозу нәтиҗәсендә саналган һәм түләнгән процентларны түләүгә киткән чыгымнарныц бер олешен каплау өчен субсидияләр бирелми.

Бурычка алучы кредитны (займны) чит ил валютасында алган очракта, чыгымнарның бер өлешен каплау өчен акчалар чит ил валютасына карата кредит буенча процентларны түләү датасына Россия Федерациясе Үзәк банкы билгеләгән рубль курсыннан чыгып бирелә. Чыгымнарның бер өлешен каплауга карата акча күләмен исәпләгәндә чит ил валютасында алынган кредит (займ) буенча чик күләме елына 10,5 процент күләмендә, ә 2015 елның 1 гыйнварыннан соң алынган кредитлар (займнар) буенча елына 10 проценттан артмаган дәрәҗәдә билгеләнә торган процент ставкасы кулланыла.

9. Субсидияләрнең күләме Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслаулау ставкасы (исәпкә алу ставкасы) буенча максатчан билгеләнеше буенча файдаланылган, кредит шартнамәсен (займ шартнамәсен) төзү датасына, ә кредиттан (займнан) файдалану өчен түләү күләме үзгәртелүгә бәйле кредит шартнамәсенә (займ шартнамәсенә) карата өстәмә килешү төзегән очракта, – кредит шартнамәсенә (займ шартнамәсенә) карата өстәмә килешү төзү датасына гамәлдә булган кредит (займ) суммасыннан чыгып исәпләнә.

10. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе (алга таба – Идарә) бурычка алучыдан түбәндәге документларны кабул итеп ала:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирелү турында гариза;

кредит оешмасы тарафыннан таныкланган кредит шартнамәсенең (займ шартнамәсенең), кредит (займ) алу турында ссуда счетыннан өземтәнең, аның буенча түләү һәм процентларны түләү графигының күчермәләре;

шушы боерыкка карата 11 пункт нигезендәге исемлек буенча кредиттан (займнан) максатчан файдалануны раслый торган документларның бурычка алучы тарафыннан таныкланган күчермәләре, – кредиттан файдалану дәрәҗәсенә карап;

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданның шәхси ярдәмче хуҗалыгын исәпкә алу турында авыл хуҗалыгы кенәгәсеннән алынган өземтә.

Шушы пунктта күрсәтелгән документлар 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап бурычка алучы тарафыннан кредит шартнамәсенең гамәлдәге вакыты чыкканнан соң 6 айдан да соңга калмыйча тапшырылырга тиешле.

11. Бурычка алучы Идарәгә түбәндәге документларны тапшыра:

а) авыл хуҗалыгы өчен кече габаритлы техника, егәрлеге 100 ат көченә кадәр булган тракторлар һәм алар белән агрегатлана торган авыл хуҗалыгы машиналары, йөк ташый торган, тулы массасы 3,5 тоннадан артмаган автомобильләр сатып алуга алынган кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча:

сату-алу шартнамәләренең, накладная кәгазьләренең яки товар чекларының күчермәләре;

авыл хуҗалыгы өчен кече габаритлы техниканы, йөк ташучы автомобильләрне, тракторларны, авыл хуҗалыгы машиналарын һәм җайланмаларны оешмалардан, берәмтекләп сатучы нокталардан яки шәхси эшмәкәрләрдән сатып алган очракта түләү йөкләмәләренең, касса чекларының яки керемнәр буенча касса ордерларының күчермәләре;

авыл хуҗалыгы өчен кече габаритлы техниканы, йөк ташучы автомобильләрне, тракторларны, авыл хуҗалыгы машиналарын һәм җайланмаларны физик затлардан кәгазь акчага сатып алган очракта сату-алу шартнамәләренең, бурычка алучыдан акчаларны алу турында сатучылардан (китерүчеләрдән) язунамәләрнең күчермәләре;

юл хәрәкәте иминлеге буенча дәүләт инспекциясе органнарында һәм дәүләт техника күзәтчелеге органнарында теркәлүе турындагы тамга белән транспорт чарасының паспорт күчермәләре;

муниципаль берәмлекнең башкарма комитетыннан – шәһәр һәм авыл җирлекләреннән (алга таба – башкарма комитет) авыл хуҗалыгы кенәгәләреннән белешмә-өземтәләр.

Авыл хуҗалыгы терлекләрен, терлекчелек һәм авыл хуҗалыгы продуктларын эшкәртү өчен җайланмалар сатып алу, шулай ук терлекчелек биналарын ремонтлау, үзгәртеп кору һәм төзү, газ җайланмасы сатып алу һәм, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан алынган кредитның (займның) гомуми суммасы агымдагы елда бер хуҗалыкка 700 мең сумнан артып китмәгән шарт белән, газ челтәрләренә тоташтыру өчен алынган кредитлар (займнар) буенча:

сату-алу шартнамәләренең, накладная кәгазьләренең яки товар чекларының күчермәләре;

авыл хуҗалыгы терлекләрен сатып алган очракта түләү йөкләмәләренең, касса чекларының яки керемнәр буенча касса ордерларының күчермәләре;

авыл хуҗалыгы терлекләрен физик затлардан кәгазь акчага сатып алган очракта сату-алу шартнамәләренең, бурычка алучыдан акчаларны алу турында сатучылардан (китерүчеләрдән) язунамәләрнең күчермәләре;

башкарма комитетның авыл хуҗалыгы кенәгәсеннән, авыл хуҗалыгы терлекләрен сатып алганда, аларның хәрәкәте турында белешмә-өземтәләр;

күләмнәрен һәм файдаланыла торган материалларны күрсәтеп, төзелә торган яки үзгәртеп корыла торган терлекчелек биналарының бурычка алучы тарафыннан имзаланган схемасы;

бурычка алучы тарафыннан тутырылган һәм имзаланган, башкарма комитет тарафыннан расланган чыгымнар сметасы (белешмәсе);

чыгымнар сметасы (белешмәсе) буенча сатып алынган материалларга карата касса чекларының, керем буенча касса ордерларының, товар накладная кәгазьләренең яки товар чекларының күчермәләре;

терлекчелек биналарын үзгәртеп кору, модернизацияләү һәм төзү буенча (подряд ысулы белән) эшләр башкарылуга карата шартнамәләрнең, терлекчелек биналарын үзгәртеп кору, модернизацияләү һәм төзү буенча башкарылган эшләр турында актларның һәм башкарылган эшләргә түләгәнлекне раслый торган түләү документларының күчермәләре;

җайланма алуга карата накладная кәгазьләренең (товар чекларының) һәм газ җайланмасы, материаллары өчен түләгәнлекне раслый торган түләү документларының күчермәләре;

башкарылган эшләр турындагы актларның һәм газ челтәрләренә тоташтырганда башкарылган эшләргә түләгәнлекне раслый торган түләү документларының күчермәләре.

Ягулык-майлау материаллары, авыл хуҗалыгы техникасын һәм терлекчелек биналарын ремонтлау өчен запас өлешләр һәм материаллар, минерал ашламалар, үсемлекләрне, терлек азыкларын саклау чаралары, ветеринария препаратлары һәм авыл хуҗалыгы эшләрен башкару өчен башка матди ресурслар, шул исәптән теплицалар, яшь авыл хуҗалыгы терлекләре өчен материаллар сатып алуга, шулай ук, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан алынган кредитның (займның) гомуми суммасы агымдагы елда бер хуҗалыкка 300 мең сумнан артып китмәгән шарт белән, авыл хуҗалыгы продуктларын иминиятләштергән очракта иминият кертемнәрен түләүгә алынган кредитлар (займнар) буенча:

сату-алу шартнамәләренең, накладная кәгазьләренең яки товар чекларының күчермәләре;

түләү йөкләмәләренең, касса чекларының яки матди ресурсларны юридик затлардан яки шәхси эшмәкәрләрдән сатып алган очракта керем буенча касса ордерларының күчермәләре;

яшь авыл хуҗалыгы терлекләрен һәм терлек азыгын физик затлардан кәгазь акчага сатып алган очракта сату-алу шартнамәләренең, бурычка

алучыдан акчаларны алу турында сатучылардан (китерүчеләрдән) язунамәләрнең күчермәләре;

иминиятләштерү шартнамәсенең һәм иминият кертемнәрен түләү буенча түләү документларының күчермәләре;

товар-матди кыйммәтләр һәм топ чаралар бурычка алучы белән бергә яшәми торган һәм/яки аның белән уртак шәхси ярдәмче хуҗалык алып бармый торган физик затлардан сатып алынырга тиеш. Бурычка алучы – шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан булганда яки бурычка алучы белән яшәүче һәм (яки) аның белән бергә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы физик затлар бер үк вакытта шәхси эшмәкәр булган очракта, товар-матди кыйммәтләр һәм төп чаралар бүтән шәхси эшмәкәрләрдән сатып алынырга тиеш;

башкарма комитетның авыл хуҗалыгы кенәгәсеннән белешмә-өземтәләр.

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслаган исемлек нигезендә, халык кәсепчелеген, авыл җирлегендә сәүдәлекне үстерүне кертеп, авыл җирлегендә туристлыкны (авылда туристлыкны), шулай ук авыл халкына көнкүреш һәм социаль-мәдәни хезмәт күрсәтүгә, кыргый үсүче җимешләрне, җиләкләрне, дару үләннәрен һәм башка азык-төлек һәм агач булмаган урман ресурсларын әзерләүгә һәм эшкәртүгә бәйле юнәлешләрне үстерүгә алынган кредитлар (займнар) буенча:

бурычка алучы тарафыннан төзелгән һәм имзаланган, башкарма комитет тарафыннан расланган чыгымнар сметасы (белешмәсе);

чыгымнар сметасы (белешмәсе) буенча сатып алынган материалларга касса һәм (яки) товар чекларының күчермәләре;

объектларны үзгәртеп кору, модернизацияләү һәм төзү буенча (подряд ысулы белән) эшләр башкарылуга карата шартнамәләрнең, объектларны үзгәртеп кору, модернизацияләү һәм төзү буенча башкарылган эшләр турында актларның һәм башкарылган эшләргә түләгәнлекне раслый торган түләү документларының күчермәләре;

башкарма комитетның авыл хуҗалыгы кенәгәсеннән белешмә-өземтәләр.

б) авыл хуҗалыгы техникасы һәм җайланмасы, шул исәптән тракторлар һәм аның белән агрегатлана торган авыл хуҗалыгы машиналары, терлекчелек, кошчылык, терлек азыгы җитештерү өчен кулланыла торган җайланмалар, яңгыр яудыра һәм су сиптерә торган машиналар, җайланмалар һәм аппаратлар, насос станцияләре, йөк автомобильләрен, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын газ-мотор ягулыгына күчерү өчен җайланмалар сатып алуга алынган кредитлар (займнар) буенча;

авыл хуҗалыгы техникасын һәм җайланмасын сатып алу турында (лизинг) шартнамәләрнең күчермәләре;

авыл хуҗалыгы техникасы һәм җайланмасы өчен түләгәнлекне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

авыл хуҗалыгы техникасы һәм җайланмасы сатып алуга карата товар-транспорт накладная кәгазьләренең, счет-фактураларның күчермәләре;

юл хәрәкәте иминлеге буенча дәүләт инспекциясе органнарында һәм дәүләт техника күзәтчелеге органнарында теркәлүе турындагы тамга белән транспорт чараларының паспорт күчермәләре.

Авыл хуҗалыгы техникасын һәм җайланмасын чит ил валютасында сатып алуны раслый торган документлар:

чит илнең авыл хуҗалыгы техникасын һәм җайланмасын сатып алуга контракт күчермәсе;

авыл хуҗалыгы техникасы һәм җайланмасы өчен түләү буенча түләү йөкләмәләренең һәм (яки) аккредитив ачылуны раслый торган документларның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

бурычка алучы тарафыннан таныкланган, валюта күчерүне раслау турында свифт хәбәрләре күчермәләре;

йөк таможня декларациясе күчермәсе (законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә йөк таможня декларациясен рәсмиләштергәннән соң бирелә);

импорт алыш-бирешенең паспорт күчермәсе;

импорт алыш-бирешенең паспорт торышы турында белешмә.

юл хәрәкәте иминлеге буенча дәүләт инспекциясе органнарында һәм дәүләт техника күзәтчелеге органнарында теркәлүе турындагы тамга белән транспорт чараларының паспорт күчермәләре.

Авыл хуҗалыгы продуктларын саклауга һәм эшкәртүгә, нәселле авыл хуҗалыгы терлекләрен, нәселле продуктлар (материал) сатып алуга, бәрәңге, яшелчә һәм җиләк-җимеш саклый торган биналарны, ябык грунтта җимешле-яшелчәле продуктлар җитештерү буенча комплексларны, терлекчелек комплексларын (фермалар), терлекчелек, терлек азыгын җитештерү объектларын һәм җитенне һәм җитен җепселен эшкәртү буенча объектларны төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә, агымдагы елда алынган кредитның (займның) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 10 миллион сумнан артып китмәү шарты белән, прививка комплексларын төзүне һәм үзгәртеп коруны да кертеп, күп еллык утыртмалар өчен прививка комплексларын төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә һәм күп еллык утыртмаларны һәм виноградлыкларны утыртуга алынган кредитлар (займнар) буенча:

нәселле авыл хуҗалыгы терлекләрен, нәселле продуктлар (материал) сатып алу турында (лизинг) шартанмә күчермәсе;

нәселле авыл хуҗалыгы терлекләре, нәселле продуктлар (материал) өчен түләгәнлекне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

нәселле авыл хуҗалыгы терлекләрен, нәселле продуктларны (материалны) кабул итеп алу-тапшыру актлары күчермәләре;

нәселле авыл хуҗалыгы терлекләрен, нәселле продуктлар (материал) сатып алуга карата нәселле таныклыкларның күчермәләре.

Авыл хуҗалыгы терлекләрен, нәселле продуктларны (материалны) чит ил валютасында сатып алуны раслый торган документлар:

авыл хуҗалыгы терлекләрен, нәселле продуктларны (материалны) сатып алуга контракт күчермәсе;

авыл хуҗалыгы терлекләре, нәселле продуктлар (материал) өчен түләүгә карата түләү йөкләмәләренең һәм (яки) аккредитив ачылуны раслый торган документларның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валюта күчерүне раслау турында свифт хәбәрләре күчермәләре;

йөк таможня декларациясе күчермәсе (законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә йөк таможня декларациясен рәсмиләштергәннән соң бирелә);

импорт алыш-бирешенең паспорт күчермәсе;

авыл хуҗалыгы терлекләренең, нәселле продуктларның (материалның) нәсел кыйммәтен раслый торган документлар күчермәләре;

төзелешнең титул исемлеге күчермәсе;

объектны төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә җыелма смета күчермәсе;

технологик җайланма китертүгә, подряд эшләрен башкаруга шартанмәләрнең, төзү-монтажлау эшләре башкарылу графигының күчермәләре.

Эшләрнең графигы үтәлү дәрәҗәсенә карап тапшырыла торган доументлар:

технологик җайланма өчен, башкарылган эшләр өчен, эшләр подряд ысулы белән башкарылганда, төзелеш материаллары һәм чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләгәнлекне раслый торган түләү йөкләмәләренең, аванс түләүләрен дә кертеп, кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

башкарылган эшләр актларының күчермәләре;

бинаны (корылманы) файдалануга кабул итеп алу-тапшыру турында актларның күчермәләре (төзелеш беткәннән соң бирелә, шул ук вакытта субсидия бурычка алучыга эшләрнең этаплары башкарылу дәрәҗәсенә карап түләнә).

Күп еллык утыртмаларны һәм виноградлыкларны утыртканда:

утырту материаллары һәм (яки) шпалерлар урнаштыру өчен материаллар өчен түләгәнлекне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

утырту материалы өчен түләү йөкләмәләренең һәм (яки) аның өчен түләүгә аккредитив ачылганлыгын раслый торган документларның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валюта күчерүне раслау турында свифт хәбәрләре күчермәләре;

йөк таможня декларациясе күчермәсе (законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә йөк таможня декларациясен рәсмиләштергәннән соң бирелә);

импорт алыш-бирешенең паспорт күчермәсе;

утырту эшләрен кабул итеп алу актларының күчермәләре (эшләр тәмамланганнан соң).

Ягулык-майлау материаллары, авыл хуҗалыгы техникасын һәм терлекчелек биналарын ремонтлау өчен запас өлешләр һәм материаллар, минерал ашламалар, үсемлекләрне, терлек азыкларын саклау чаралары, ветеринария препаратлары һәм сезонлы эшләр башкару өчен башка матди ресурслар, яшь авыл хуҗалыгы терлекләре сатып алуга, шулай ук, агымдагы елда алынган кредитның (займның) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 5 миллион сумнан артып китмәгән шарт белән, авыл хуҗалыгы продуктларын иминиятләштергән очракта иминият кертемнәрен түләүгә алынган кредитлар (займнар) буенча:

сезонлы эшләр башкаруга матди ресурслар, яшь авыл хуҗалыгы терлекләрен сатып алуга шартнамәләрнең күчермәләре, – түләү йөкләмәсендә "түләүнең билгеләнеше" графасында түләү өчен нигез буларак күрсәтелгән очракта тапшырыла;

терлек азыгын, ягулык-майлау материалларын һәм запас өлешләрне сатып алганда түләү йөкләмәләренең яки керем буенча касса ордерларының (юридик затлардан яки шәхси эшмәкәрләрдән сатып алганда), шулай ук башка сатып алына торган матди ресурслар өчен түләү буенча түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

накладная кәгазьләренең яки товар чекларының күчермәләре.

Авыл хуҗалыгы продуктларын иминиятләштерү өчен:

иминиятләштерү шартнамәсенең күчермәсе;

иминият кертемнәрен түләү буенча түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре.

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә, халык кәсепчелеген, авыл җирлегендә сәүдәлекне үстерүне кертеп, авыл җирлегендә туристлыкны (авылда туристлыкны), шулай ук авыл халкына көнкүреш һәм социаль-мәдәни хезмәт күрсәтүгә, кыргый үсүче җимешләрне, җиләкләрне, дару үләннәрен һәм башка азык-төлек һәм агач булмаган урман ресурсларын әзерләүгә һәм эшкәртүгә бәйле юнәлешләрне үстерүгә алынган кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча:

төзелешнең титул исемлеге күчермәсе;

объектны төзүгә, үзгәртеп коруга, модернизацияләүгә җыелма смета күчермәсе.

Технологик җайланма китертүгә, подряд эшләре, бүтән эшләр (проект эшләре, экспертиза, техник күзәтчелек) башкарылуга шартнамәләрнең, төзү-монтажлау эшләрен башкару графигы күчермәләре.

Эшләрнең графигын үтәү дәрәҗәсенә карап тапшырыла торган документлар:

кредит оешмасы тарафыннан расланган, технологик җайланмалар, бүтән эшләр (проект эшләре, экспертиза, техник күзәтчелек) өчен түләгәнлекне һәм эшләрне башкаруга карата, шул исәптән аванс түләүләре буенча подрядчыларга акча күчергәнлекне раслый торган түләү йөкләмәләренең күчермәләре;

башкарылган эшләр актларының күчермәләре;

бинаны (корылманы) файдалануга кабул итеп алу-тапшыру турында актларның күчермәләре (төзелеш беткәннән соң бирелә, шул ук вакытта субсидия бурычка алучыга эшләрнең этаплары башкарылу дәрәҗәсенә карап түләнә).

Транспорт чараларын, техниканы һәм җайланмаларны чит ил валютасында сатып алуны раслый торган документлар:

сатып алуга карата контрактның күчермәсе;

түләү йөкләмәләренең һәм (яки) аккредитив ачуны раслый торган документларның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валютада акча күчергәнлекне раслый торган свифт хәбәрләренең күчермәләре;

йөк таможня декларациясе күчермәсе (законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә йөк таможня декларациясен рәсмиләштергәннән соң бирелә);

импорт алыш-биреше паспорты күчермәсе;

юл хәрәкәте иминлеге буенча дәүләт инспекциясе органнарында һәм дәүләт техника күзәтчелеге органнарында теркәлүе турындагы тамга белән транспорт чараларының паспорт күчермәләре.

Кирәкле җайланмалар, матди ресурслар, транспорт чаралары һәм инвентарь сатып алу өчен алынган кредит шартнамәләре (займ шартнамәләре) буенча:

сату-алу шартнамәләренең, накладная кәгазьләренең яки товар чекларының күчермәләре;

түләү йөкләмәләренең, касса чекларының яки оешмалардан, берәмтекләп сату нокталарыннан яки шәхси эшмәкәрләрдән сатып алган очракта керем буенча касса ордерларының күчермәләре, шулай ук юл хәрәкәте иминлеге буенча дәүләт инспекциясе органнарында һәм дәүләт техника күзәтчелеге органнарында теркәлүе турындагы тамга белән транспорт чараларының паспорт күчермәләре.

Кыргый үсә торган җимешләрне, җиләкләрне, дару үләннәрен һәм бүтән азык-төлек һәм агач булмаган урман ресурсларын (алга таба – кыргый үсемлекләр) сатып алганда:

кыргый үсемлекләрне сатып алу турында шартнамәләрнең бурычка алучы тарафыннан таныкланган күчермәләре, сатып алынган кыргый үсемлекләр өчен түләү йөкләмәләренең күчермәләре, оешмалардан һәм шәхси эшмәкәрләрдән сатып алган очракта;

билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән сатып алу актларының күчермәләре яки, физик затлардан сатып алганда, сатып алынган кыргый үсемлекләр өчен түләгәнлекне раслый торган накладная кәгазьләренең һәм документларның күчермәләре;

кредит шартнамәсенең (займ шартнамәсенең) гамәлдә булган чорында рәсмиләштерелгән, авыл хуҗалыгына бәйле булмаган тиешле эшчәнлек төрләрен башкаруны раслый торган документлар.

в) техника һәм җайланма (Россиядә һәм чит илдә җитештерелгәнне), шул исәптән терлек азыкларын, инкубатор күкәйләрен, чебешләрне, нәселле

бозауларны һәм кош көтүлекләрен ташу өчен махсус транспорт, тракторлар һәм алар белән агрегатлана торган авыл хуҗалыгы машиналары, терлекчеклек, кошчылык, терлек азыгы җитештерү өчен җайланмалар, йөк машиналарын, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын газ-мотор ягулыгына күчерә торган җайланмалар сатып алуга алынган кредит шартнамәләре (займнар) буенча:

техника һәм җайланма сатып алуга (лизинг) шартнамәләрнең күчермәләре;

техника һәм җайланма өчен түләгәнлекне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

техника һәм җайланма сатып алуга карата товар-транспорт накладная кәгазьләренең, счет-фактураларның күчермәләре;

техника һәм җайланма сатып алуга карата товар-транспорт накладная кәгазьләренең күчермәләре;

юл хәрәкәте иминлеге буенча дәүләт инспекциясе органнарында һәм дәүләт техника күзәтчелеге органнарында теркәлүе турындагы тамга белән транспорт чараларының паспорт күчермәләре.

Техниканы һәм җайланманы чит ил валютасында сатып алуны раслый торган документлар:

Импорт техникасы, транспорты һәм җайланмасы сатып алуга карата контрактның күчермәсе;

түләү йөкләмәләренең һәм (яки) аккредитив ачуны раслый торган документларның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валютада акча күчергәнлекне раслый торган свифт хәбәрләренең күчермәләре;

йөк таможня декларациясе күчермәсе (законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә йөк таможня декларациясен рәсмиләштергәннән соң бирелә);

импорт алыш-биреше паспорты күчермәсе;

транспорт чараларын сатып алганда билгеләнгән тәртиптә исәпкә алынуы турындагы тамга белән транспорт чараларының паспорт күчермәләре.

Махсус технологик җайланма, суыткыч җайланмасы, авыл хуҗалыгы терлекләре, нәселле продуктлар (материал) сатып алу, шул исәптән аларны кооператив әгъзаларына китерү өчен, бәрәңге, яшелчә һәм җиләк-җимеш саклый торган биналарны, ябык грунтта җимешле-яшелчәле продуктлар җитештерү буенча комплексларны, терлекчелек, терлек азыгы җитештерү объектларын һәм җитен белән җитен җепселен эшкәртү объектларын төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә, базарларны, сәүдә урыннарын, сөтне, итне, яшелчә-җиләк-җимеш продуктларын кабул итеп алу, беренчел эшкәртү һәм саклау буенча пунктларны төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә, шулай ук күп еллык утыртмаларны һәм виноградлыкларны утыртуга, агымдагы елда алынган кредитның (займның) гомуми суммасы бер кооперативка 40 миллион сумнан артып китмәгән шарт

белән, күп еллык утыртмалар өчен прививка комплексларын төзүгә һәм үзгәртеп коруга алынган кредитлар (займнар) буенча:

төзелешнең титул исемлеге күчермәсе;

объектларныны төзүгә һәм (яки) үзгәртеп коруга һәм (яки) модернизацияләүгә җыелма смета күчермәсе;

технологик җайланма китертүгә, подряд эшләрен башкаруга шартнамәләрнең, төзү-монтажлау эшләрен башкару графигының күчермәләре.

Бурычка алучы тарафыннан эшләрнең графигы үтәлү дәрәҗәсенә карап тапшырыла торган документлар:

подряд ысулы белән эшләр башкарганда, технологик җайланма, башкарылган эшләр өчен түләгәнлекне раслый торган, аванс түләүләрен дә исәпкә алып, түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган, ә эшләрне хуҗалык ысулы белән башкарганда, төзелеш материаллары һәм чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләгәнлекне раслый торган түләү йөкләмәләренең бурычка алучы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

башкарылган эшләр турында актларның бурычка алучы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

бинаны (корылманы) файдалануга кабул итеп алу-тапшыру турында актларның күчермәләре (төзелеш беткәннән соң бирелә, шул ук вакытта субсидия бурычка алучыга эшләрнең этаплары башкарылу дәрәҗәсенә карап түләнә).

Күп еллык утыртмаларны һәм виноградлыкларны утыртуга алынган кредитлар (займнар) буенча:

утыртма материал һәм (яки) шпалерлар урнаштыру өчен материаллар өчен түләгәнлекне раслый торган, аванс түләүләрен дә кертеп, түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

утыртманы кабул итү актларының бурычка алучы тарафыннан таныкланган күчермәләре (эшләр тәмамланганнан соң);

утырту материалын чит ил валютасында сатып алганлыкны раслый торган документлар;

утырту материалын сатып алуга карата бурычка алучы тарафыннан таныкланган шартнамә күчермәсе;

утырту материалы очен түләү йөкләмәләренең һәм (яки) аккредитив ачылганлыгын раслый торган документларның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валютаны күчерүне раслау турында свифт хәбәрләре күчермәләре;

йөк таможня декларациясе күчермәсе (законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә йөк таможня декларациясен рәсмиләштергәннән соң бирелә);

импорт алыш-бирешенең паспорт күчермәсе;

утыртманы кабул итеп алу актларының күчермәләре (эшләр тәмамланганнан соң).

Авыл хуҗалыгы терлекләрен, нәселле продуктлар (материал) сатып алуга алынган кредит шартнамәләре (займнар) буенча:

авыл хуҗалыгы терлекләрен, нәселле продуктлар (материал) сатып алу турында (лизинг) шартанмә күчермәсе;

авыл хуҗалыгы терлекләре, нәселле продуктлар (материал) өчен түләгәнлекне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

авыл хуҗалыгы терлекләрен, нәселле продуктларны (материалны) кабул итеп алу-тапшыру актлары күчермәләре;

авыл хуҗалыгы терлекләрен, нәселле продуктлар (материал) сатып алуга карата нәселле таныклыкларның күчермәләре.

Авыл хуҗалыгы терлекләрен, нәселле продуктларны (материалны) чит ил валютасында сатып алганлыкны раслый торган документлар:

авыл хуҗалыгы терлекләрен, нәселле продуктларны (материалны) сатып алуга контракт күчермәсе;

авыл хуҗалыгы терлекләре, нәселле продуктлар (материал) өчен түләүгә карата түләү йөкләмәләренең һәм (яки) аккредитив ачылуны раслый торган документларның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валюта күчерүне раслау турында свифт хәбәрләре күчермәләре;

йөк таможня декларациясе күчермәсе (законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә йөк таможня декларациясен рәсмиләштергәннән соң бирелә);

импорт алыш-бирешенең паспорт күчермәсе;

авыл хуҗалыгы терлекләренең, нәселле продуктларның (материалның) нәсел кыйммәтен раслый торган документлар күчермәләре.

Сезонлы эшләрне башкару өчен матди ресурслар, яшь авыл хуҗалыгы терлекләре, сәнәгый эшкәртү өчен үзебезнең илдә җитештерелгән авыл хуҗалыгы чималы (2013 елдан башлап – беренчел һәм сәнәгый эшкәртү өчен авыл хуҗалыгы чималы) сатып алуга, кооператив әгъзалары җитештергән авыл хуҗалыгы продуктларын алга таба аны сату өчен сатып алуга, шулай ук кооперативны оешкан төстә җиһазландыруга һәм, агымдагы елда алынган кредитның (займның) гомуми суммасы бер кооперативка 15 миллион сумнан артып китмәгән шарт белән, аыыл хуҗалыгы продуктларын иминиятләштергәндә иминият кертемнәрен түләүгә алынган кредит шартнамәләре (займнар) буенча:

сезонлы эшләрне башкару өчен матди ресурслар, яшь авыл хуҗалыгы терлекләрен сатып алуга карата шартнамәләрнең яки товар-транспорт накаладная кәгазьләренең күчермәләре;

терлек азыгы, ягулык-майлау материаллары һәм запас өлешләр сатып алганда түләү йөкләмәләренең, товар чекларының кредит оешмасы тарафыннан таныкланган яки керем буенча касса ордерларының (оешмалардан, берәмтекләп сату нокталарыннан яки шәхси эшмәкәрләрдән сатып алган очракта) бурычка алучы тарафыннан таныкланган, шулай ук сатып алына торган башка матди ресурслар һәм яшь авыл хуҗалыгы терлекләре өчен түләүдәүге түләү йөкләмәләренең күчермәләре.

Беренчел һәм сәнәгый эшкәртү өчен үзебезнең илдә житештерелгән чимал (алга таба – чимал) сатып алуга, шулай ук кооператив әгъзаларыннан авыл хуҗалыгы продуктларын (алга таба - продуктлар) сатып алганда:

чимал, продуктлар сатып алуга карата шартнамәләрнең күчермәләре, сатып алына торган чимал, продуктлар өчен түләүдә түләү йөкләмәләренең бурычка алучы тарафыннан таныкланган күчермәләре, юридик затлардан һәм шәхси эшмәкәрләрдән сатып алган очракта;

сатып алу актларының күчермәләре, накладная кәгазьләренең һәм, физик затлардан сатып алган очракта, сатып алынган чимал өчен түләгәнлекне раслый документларның күчермәләре.

Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативын оешкан рәвештә җиһазлау өчен алынган кредитлар (займнар) буенча, авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативын да кертеп:

шартнамәләрнең, товар-транспорт накладная кәгазьләренең күчермәләре;

мебель, оргтехника, шул исәптән программа продуктларын, элемтә чаралары сатып алуга, интернет челтәренә тоташтыруга, офис биналарының арендасы өчен түләүгә, коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә түләү йөкләмәләренең, товар чекларының, касса чекларының яки керем буенча касса ордерларының (юридик затлардан, берәмтекләп сату нокталарыннан яки шәхси эшмәкәрләрдән сатып алган очракта) кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре.

Авыл хуҗалыгы продуктларын иминиятләштерүгә:

иминиятләштерү шартнамәсенең күчермәсе;

иминият кертемнәрен түләү буенча түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре.

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслаган исемлек нигезендә, халык кәсепчелеген, авыл җирлегендә сәүдәлекне үстерүне кертеп, авыл җирлегендә туристлыкны (авылда туристлыкны), шулай ук авыл халкына көнкүреш һәм соңиаль-мәдәни хезмәт күрсәтүгә, кыргый үсүче җимешләрне, җиләкләрне, дару үләннәрен һәм башка азык-төлек һәм агач булмаган урман ресурсларын әзерләүгә һәм эшкәртүгә бәйле юнәлешләрне үстерүгә алынган кредитлар (займнар) буенча:

төзелешнең титул исемлеге күчермәсе;

объектны төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә җыелма смета күчермәсе;

технологик җайланма китертүгә, подряд эшләрен, бүтән эшләрне (проект эшләре, экспертиза, техник күзәтчелек) башкаруга шартанмәләрнең, төзү-монтажлау эшләре башкарылу графигының күчермәләре.

Эшләрнең графигы башкарылу дәрәҗәсенә карап тапшырыла торган документлар:

подряд ысулы белән башкарылган эшләр, бүтән төрле эшләр (проект эшләре, экспертиза, техник надзор) өчен, эшләрне хуҗалык ысулы белән башкарганда төзелеш материаллары һәм чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләгәнлекне раслый торган түләү йөкләмәләренең, аванс түләүләрен дә

кертеп, кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре һәм төп нөсхәләре;

башкарылган эшләр актларының күчермәләре;

бинаны (корылманы) файдалануга кабул итеп алу-тапшыру турында актларның күчермәләре (төзелеш беткәннән соң бирелә, шул ук вакытта субсидия эшләрнең этаплары башкарылу дәрәҗәсенә карап түләнә).

Транспорт чарасын, техниканы һәм җайланманы чит ил валютасында сатып алганлыкны раслый торган документлар:

сатып алуга карата контрактның күчермәсе;

түләү йөкләмәләренең һәм (яки) аккредитив ачуны раслый торган документларның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валютада акча күчергәнлекне раслый торган свифт хәбәрләренең күчермәләре;

йөк таможня декларациясе күчермәсе (законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә йөк таможня декларациясен рәсмиләштергәннән соң бирелә);

импорт алыш-биреше паспорты күчермәсе;

импорт алыш-биреше паспортының торышы турында белешмә;

юл хәрәкәте иминлеге буенча дәүләт инспекциясе органнарында һәм дәүләт техника күзәтчелеге органнарында теркәлүе турындагы тамга белән транспорт чараларының паспорт күчермәләре.

Кирәкле җайланмалар, матди ресурслар, транспорт чаралары һәм инвентарь сатып алуга алынган кредит шартнамәләре (займнар) буенча:

сату-алу шартнамәләренең, накладная кәгазьләренең яки товар чекларының күчермәләре;

түләү йөкләмәләренең, касса чекларының яки оешмалардан, берәмтекләп сату нокталарыннан яки шәхси эшмәкәрләрдән сатып алган очракта керем буенча касса ордерларының күчермәләре, шулай ук юл хәрәкәте иминлеге буенча дәүләт инспекциясе органнарында һәм дәүләт техника күзәтчелеге органнарында теркәлүе турындагы тамга белән транспорт чараларының паспорт күчермәләре.

Кыргый үсә торган җимешләрне, җиләкләрне, дару үләннәрен һәм бүтән азык-төлек һәм агач булмаган урман ресурсларын (алга таба – кыргый үсемлекләр) сатып алу өчен алынган кредит шартнамәләре (займнар) буенча:

сатып алу турында шартнамәләрнең күчермәләре, түләү йөкләмәләренең күчермәләре, оешмалардан һәм шәхси эшмәкәрләрдән сатып алган очракта;

билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән сатып алу актларының күчермәләре яки, физик затлардан сатып алганда, түләгәнлекне раслый торган накладная кәгазьләренең һәм документларның күчермәләре.

Искәрмә:

кредитны (займны) чит ил валютасында алганда һәм аны сумнарда файдаланган очракта, максатчан файдалануны раслый торган документлар исемлеге сумнарда алынган кредиттан (займнан) максатчан файдалануны раслау өчен билгеләнгән документлар исемлегенә туры килә.

12. Идарәләр:

а) субсидияләр бирелү турында гаризаларны кергән көнендә дәфтәрдә теркиләр, ул номерлана, тегелә һәм мөһер белән беркетелә;

б) шушы Тәртипнең 10-11 пунктлары нигезендә тапшырылган документларны гаризаны теркәгән көннән башлап биш конлек чорда карап тикшерә;

в) Министрлыкка Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча субсидияләр бирелүгә карата җыелма белешмә-исәпләмәләр тапшыра;

г) 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап бурычка алучы тарафыннан шушы Тәртипнең 10-11 пунктлары нигезендәге документлар кредит шартнамәсенең гамәлдәге вакыты узгач 6 айдан да соңга калмыйча тапшырыла;

д) Министрлык тарафыннан расланган рәвештә, бурычка алучылар белән Министрлык арасында Субсидия бирелү турында килешү (алга таба – Килешү) төзи, анда субсидияләр бирелүнең мәҗбүри шарты булып бурычка алучыларның Министрлык һәм дәүләт финанс контрольлеге органнары тарафыннан субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүгә ризалык бирүе тора.

Субсидияне бирүдән баш тарту очен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларны тулы булмаган күләмдә тапшыру;

бюджет йөкләмәләре лимитында калдык өлеш булмау.

Субсидияләрне бирүдән баш тарту законнарда каралган тәртиптә шикаять кылынырга мөмкин.

13. Министрлык бюджет акчаларын төп бүлүче булып тора һәм, Министрлык раслаган рәвештә хисапланган субсидияләрнең күләме нигезендә, субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән башлап 10 көнлек чорда, үзенең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекләрендә ачылган лицевой счетыннан бурычка алучыларның исәп-хисап счетларына акча күчерә.

14. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.

15. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет керемено кире кайтарылырга тиеш.

16. Бу Тәртипнең 14 һәм 15 пунктларында күрсәтелгән бюджет акчаларын Татарстан Республикасының бюджет керемено ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

17. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары субсидияләрне алучыларга субсидияләр бирү шартларын,

максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

18. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе Россия кредит оешмаларыннан алынган кредитлар һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларыннан алынган займнар буенча процентларны түләүдә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләрдән ирекле рәвештә баш тарткан очракта, акчалар Россия Федерациясе бюджетына һәм Татарстан Республикасы бюджетына хисап елыннан соң килүче елның 1 декабренә кадәр кайтарып бирелергә тиеш.

19. Министрлык счетларында хисаплы финанс елында файдаланылмаган акчалар калган очракта, алар Россия Федерациясе бюджетына һәм Татарстан Республикасы бюджетына хисап елыннан соң килүче елның 1 декабренә кадәр кайтарып бирелергә тиеш.

20. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык аларның җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләнә. Закон бозучыларга карата закон нигезендә күздә тотылган җаваплылык чаралары кулланыла.

21. Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.